ОЯТЛЫ КАНУН

Тын үлемне сайларгамы, котылу сукмагына басаргамы?

> 4

ЗАМАНА ЧИРЕ

Ни өчен кеше тормыштан канәгать түгел?

> 5

АКЛАНМАГАН АЛТЫННАР

Белемеңне имтиханда күрсәтә алмасаң, «отличник» булып йөрүдән файда бармы?

> 15

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 104 (28877) | Җомга | 22 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

КАЗАН КҮЧТӘНӘЧЕ

«ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ БАШКАЛА КУНАКЛАРЫНЫҢ ХӘЛЕН БЕЛЕШТЕ

Якты чырай – тәмле сый... Быел Татарстан башкаласына киләчәк туристлар саны пандемиягә кадәрге чор күрсәткечләренә җитәр дип фаразлыйлар. Эшләр шуңа таба бара. Шәһәр үзәге – кунакларныкы. Туристларны Казан нәрсәсе белән җәлеп итә? Нәрсәне үз итәләр, кайсы ягыбыз ошамый? Бездәге бәяләр «тешлиме»? Бу һәм башка сорауларга җавап табарга тырыштык.

> 6

Ишетми калмагыз

Татарстан Министрлар Кабинеты республикада тупланган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарына кушылган егетләргә бер тапкыр бирелә торган акчаның түләү тәртибен ачыклады. Премьер-министр Алексей Песошин имзалаган карардан аңлашылганча, акча этаплап биреләчәк. Хәрби часть исемлекләренә кертелгәч, егетләр 60 мең сум алачак. Әмма ул өлешләп – һәр атна саен 15әр мең сум итеп биреләчәк. Документта күрсәтелгәнчә, акчаның күп өлеше – 200 мең сум аларга ДНР, ЛНР һәм Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашу өчен дәүләт чиген узгач күчереләчәк. Исегезгә төшерәбез: хәрби хезмәткәрләргә бер тапкыр 260 мең сум Татарстан Министрлар Кабинетының резерв фондыннан биреләчәк.

Татарстанда ковидка бәйле мәсьәләләр буенча «кайнар линия» эшли башлаганнан бирле аңа 1199826 тапкыр шалтыратканнар. Хәтерләсәгез, COVID-19 буенча тәүлек әйләнәсе эшләүче элемтә үзәге 2020 елның 25 ноябрендә ачылган иде. Үзәккә кыска номер – 122 номерын җыеп шалтыратырга мөмкин. 50дән артык оператор һәм «Лилия» исемле робот коронавирус инфекциясе, дарулар белән тәэмин итү һәм сырхауханәләр эше буенча республикада яшәүчеләрнең сорауларына җавап бирә.

«Кайнар линия» телефонына коронавируска анализларның әзерме-юкмы икәнен, аларны тапшыру урынын, поликлиникаларның эш сәгатьләрен белү өчен еш шалтыраталар. Узган елның 14 гыйнварыннан, 122 номерын җыеп, прививка ясатуга язылырга да мөмкин. Бу хезмәттән 29893 кеше файдаланган инде.

Сүз уңаеннан, узган тәүлектә Татарстанда 41 кешедә коронавирус табылган (Россиядә – 6391). Пандемия башланганнан алып республикада коронавирус инфекциясенең 153406 очрагы теркәлгән. Узган тәүлектә республикада әлеге чирдән бер үлем-китем очрагы да булмаган.

Җәй башыннан Татарстанда 25 кеше батып үлгән. Бу хакта Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе матбугат хезмәтендә хәбәр иттеләр. Суда гомере өзелгән кешеләрнең 7се – балалар. 38 кешене вакытында коткарып кала алганнар.

Татарстанга кабат эссе һава килә: ял көннәрендә температура +30 градуска җитәчәк. Шимбә – 23 июльдә кайбер районнарда аз гына яңгыр булырга мөмкин. Көндез +24...+29, төнлә +11...+16 градус. Якшәмбе – 24 июльдә тагын да эссерәк: көндез термометрның терекөмеш баганасы +25...+30 градусны күрсәтәчәк. Төнлә дә җылы: +12+17 градус.

Татарстан Гидрометеоүзәгенең башлангыч мәгълүматларына караганда, киләсе атна башында кыска вакытлы яшенле яңгыр көтелә. Көндез һава температурасы +25...+31, төнлә +13...+19 градус.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Районда «Алга» батальоны составында Оренбург өлкәсендә әзерлек узучы Түбән Кама контрактчылары өчен бүләк җыялар. Әлеге акцияне «Түбән Кама хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы һәм хатын-кыз депутатлар берләшмәсе оештырган. Атна ахырында егетләрнең хәлен белешергә район делегациясе Оренбург өлкәсенә юл тотачак. Бүләккә азык-төлек, фонарьлар, батареялар, баулар, бензин пычкысы, кер юу порошогы, бер тапкыр кулланыла торган перчаткалар, теш пасталары, щеткалар, сабын һәм башка кирәк-ярак кабул ителә.
(e-nkama.ru)

Саба

Район башкарма комитеты карары нигезендә быел 14–18 яшьлек үсмерләрне вакытлыча эшкә урнаштыруга 735 квота каралган. Былтыр ковидка бәйле сәбәпләр аркасында җәйге чорда 561 кеше эшләгән. Быел 180 укучы эшкә үзмәшгуль буларак җәлеп ителә. Авыр тормыш хәлендәге һәм күпбалалы гаиләләрдә тәрбияләнүчеләргә өстенлек бирелә. Июнь аенда район буенча 300дән артык укучы эшкә урнашкан.
(«Саба таңнары»)

Питрәч

Районда балтырганга каршы көрәш дәвам итә. Территорияләрне эшкәртү июнь ахырында башланды. Хәзергә куркыныч һәм агулы үсемлек 67,5 га территориядә чабылган. Шигалида – 50, Питрәчтә – 12, Кощакта – 2, Ленино-Кокушкинода 3,5 гектар мәйданда эшләр тәмамланган, хәзер балтырганны кечерәк участокларда чабалар. Бу эштә химик состав кулланмыйлар, чөнки биредә балтырган, нигездә, елга ярларында үсә, ә су саклау зонасында химикатлар кулланылмый.
(«Алга»)

Зәй

Район Үзәк китапханәсендә Сөббух Рәфыйков исемендәге премия тапшырылды. Әлеге бүләк милли мәдәниятне, әдәбиятны, сәнгатьне үстерүгә зур өлеш керткән, һөнәри осталыклары, үз авторлык стиле булган аерым шәхесләргә һәм коллективларга өч елга бер мәртәбә бирелә. 2022 елда конкурс комиссиясе карары белән премия лауреаты итеп җирле үзидарә органнары ветераны, районның иҗтимагый һәм мәдәни тормышы активисты Фәнзия Николаева танылды. Ул 35 елдан артык Югары Мәлем авыл советында эшли. Авылдашлары аны бүген халыкка иң якын хакимият вәкиле дип саный. Фәнзия Николаева авыл һәм районның мәдәни тормышында да актив катнаша, сәхнәдә чыгыш ясарга, район конкурсларында һәм фестивальләрендә катнашырга вакыт таба.
(zainsk.tatarstan.ru)

ОЧРАКЛЫ КЕШЕЛӘР ЮК

Казан Кремлендә хезмәт алдынгыларын кунак иттеләр. Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин аларга дәүләт бүләкләре, дәрәҗәле исемнәр тапшырды. Араларында медицина, авыл хуҗалыгы, төзелеш хезмәткәрләре, укытучылар, архитекторлар, спортчылар да бар.

– Сез тантанада очраклы кешеләр түгел. Сәләтегез, тырышлыгыгыз республиканы тагын да көчлерәк итә. Намуслы хезмәтегезгә тугры калганыгыз өчен рәхмәт, – диде Алексей Песошин, бүләкләү тантанасында.

Премьер-министр чыгышында республикадагы вазгыять белән таныштырып үтте.

– Авыр сәяси-икътисади вазгыятькә карамастан, Татарстанда халыкның яшәү дәрәҗәсе сыйфаты саклана. Сәнгатьтә, социаль өлкәдә күп проектлар тормышка ашырыла, – диде Алексей Песошин.

Кемнәр соң ул республиканы көчлерәк итүчеләр? Буа районының «Таң» җәмгыятендә машина белән саву операторы Нурдания Алимова *(рәсемдә)* «Татарстанның атказанган терлекчесе» исеменә лаек булды. Бераз аптырап та калды кебек.

– Кызым, бу бүләкнең берәр файдасы бармы соң? 40 ел стажым бар. Лаеклы ялга чыккач та 15 ел эшләдем әле. «Хезмәт ветераны» дигән исемем дә юк бит. Бу исем белән кая барып була? – дип Нурдания апа үзенекен сөйли башлады.

«Апа, мондый исем теләсә кемгә бирелми бит, сезнең хезмәтегезне лаеклы дип бәяләгәннәр, димәк», – дип аңлаткач, ирен читендә елмаю күренде.

– Без – авыл кешесе, барысын да аңлап та бетермибез инде. Ышанып та бетмим әле. Төне буе йоклый алмадым, бик нык дулкынландым. Мондый зур җиргә барганым юк бит, – ди 75 яшьлек Нурдания ханым.

Ташкичү авылында 8 нче сыйныфны тәмамлауга фермада сыер сава башлаган ул. «Иртәнге сәгать 4тә тора идек. Чиста булсын дип, сыерларны да юдык. Аларга Миләүшә, Ләйсән дигән кушаматлар тактым. Терлекнең башыннан сыйпамасаң, яратмасаң, ул сиңа сөт бирми. Кул белән көнгә 15–16 сыер саудым. Машина белән – 25 сыер. Хәзер инде ял итәм. Яшьли ирдән калдым. Өч баламны ялгыз үстердем. Тормышым җиңелләрдән булмады», – ди ул.

Лениногорск районының Тимәш авыл җирлеге башлыгы Рафаэль Сираев «Авыл җирлеген үстерүдәге хезмәте өчен» медаленә лаек булды. Ул бу җирлектә 16 ел эшли икән. Тимәш районндагы иң зур

pravtatarstan.ru

авыл булып санала. Анда 900 хуҗалык исәпләнә, 2400 кеше яши. Җирлек башлыгы мондый бүләкне көтмәгән.

– Быел республика программасы буенча фельдшер-акушерлык пункты төзелде. Элеккегесе бик иске иде. Дин галиме Утыз Имәни истәлегенә комплекс төзүне сорап, Президентка хат яздык. Безнең фикерне хуплап, моның өчен 37 миллион сум акча бүлеп бирелде. Аны октябрь аенда тапшырырга планлаштырабыз. Утыз Имәни Чирмешән районында туган, бездә яшәгән һәм җирләнгән. Комплексның бер ягы – дини, икенчесе заманча өлештән торачак, – диде ул үзгәрешләр турында.

Башлык әйтүенчә, авыл юлларына асфальт түшәлгән. Җирле салым акчасына яңартылып тора. Авыл шәһәрдән өч чакрым гына ераклыкта урнашкан. Халыкның күбесе автобус белән шунда барып эшли. Авылда купкалты йортлар да бар икән. Быел 12 ишегалды яңартылган. Моны ул авыл өчен зур яңалык дип саный.

– Авылда быел 22 бала туды. Биш ел элек 200 балага исәпләнгән яңа бакча салынды, ул сабыйлар белән тулы. Урта мәктәп бар. Бездә дә яшьләр шәһәргә китү ягын карый, – диде Рафаэль Сираев.

«Татнефть»нең технологик үсеш үзәгендә төп белгеч Рәшит Миңнуллин «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» II дәрәҗә орден медаленә ия хәзер.

– Зур бүләк бу. Беренче чиратта, укытучыларның хезмәте дип бәялим. Авыл укытучылары безне хезмәткә өйрәтте, моның җитештерүдә дә кирәге чыкты. Университетта укыганда Камчатка, Себер, Урал якларына экспедицияләргә җибәрәләр иде, – ди ул, яшьлеген искә төшереп. – 1998 елда кризис вакытында нефть бәясе 12 долларга төште. Шул вакытта безне җитәкчеләр чакырып: «Болай артка тәгәрәргә ярамый», – диделәр. Барлык технологияләрне яңартып, тормышка ашырдык. Бүген дә бар көчебезне куеп эшлибез, – ди Рәшит әфәнде.

Сәрия МИФТАХОВА

ПОЛИЦИЯГӘ ЭШ ҖИТӘРЛЕК

Татарстанда көчләү, талау, урлау, хулиганлык очраклары кимегән. Ярты ел эчендә республикада 27 меңнән артык җинаять теркәлгән. Өч очракның берсе авыр җинаять дип санала. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы 6 айлык эшчәнлегенә нәтиҗә ясады. Министрлыкның Тәтештә узган коллегия утырышында Премьер-министр Алексей Песошин да катнашты.

Министр Артем Хохорин үз чыгышында республикада шәхескә карата кылынган җинаятьләрнең фаш ителү күрсәткече зур булуын әйтте. Әйтик, үтерү, сәламәтлеккә аңлы рәвештә авыр зыян китерү, көчләү очракларының барысында да диярлек гаепле кеше табыла. Татарстанның полиция хезмәткәрләре читтән торып урлау очракларын тикшерү буенча Идел буе федераль округында – беренче, илдә дуртенче урында. Республикада банк счетыннан урлаулар – 16,6, IT-технологияләр кулланып кылынган мошенниклык очраклары 48,9 процентка күбрәк тикшерелгән. Мондый җинаятьләрне кылган кешеләр дә 14,2 һәм 28,3 процентка күбрәк ачыкланган.

Ел башыннан бирле РФ Җинаятьләр кодексының 210 маддәсе буенча (җинаятьчел бергәлек оештыру) 4 җинаять эше кузгатылган. 6 айда җинаятьчел төркемнәрнең 363 әгъзасы, шулай ук оешкан төркемнәр составында кынгыр эш кылган 96 зат җинаять җаваплылыгына тартылган.

Полиция хезмәткәрләре законсыз әйләнештән 243,7 кило наркотик һәм психотроп матдә тартып алган. Шуның 223,8 килосы – синтетик наркотик. Мондый наркотик җитештерү буенча 7 яшерен лаборатория эшчәнлеге туктатылган. Аларның 3е Татарстаннан читтә – Мәскәү, Түбән Новгород һәм Ульяновск өлкәләрендә урнашкан булган. Наркотиклар ташу өчен кулланылган 36 канал ябылган. Ел башыннан 175 мең литрга якын алкогольле һәм спиртлы ялган продукция әйләнештән алынган.

Икътисади һәм коррупциягә бәйле җинаятьләрне тикшергәндә алардан килгән зыян күләменең 34 млрд 600 млн сумнан артып киткәне ачыкланган. Бу сумманың 90 процентын кире кайтара алганнар.

Татарстанда – Цифрлаштыру елы

СҮЗДӘ ГЕНӘ КАЛМАСЫН

ЦИФРЛАШТЫРУ ЕЛЫНЫҢ ФАЙДАСЫН ҺӘРКЕМ ТОЯРГА ТИЕШ

Авыллар – интернетлы, халык – белемле, Казан «акыллы квартал»лы булсын. Цифрлаштыру елына шул максатлар куелган. Кайсыларына инде ирешелгән дә, алга таба нишләргә җыеналар? Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин республикада игълан ителгән Цифрлаштыру елының беренче нәтиҗәләре турында сөйләде.

Исеме җисеменә туры килергә тиеш. Ягъни Цифрлаштыру елының файдасын халык үз җилкәсендә дә тоярлык булсын. Министрлыкның максаты да шул.

– Цифрлаштыру елының төп максаты – Татарстанда яшәүчеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту. Цифрлаштыру елы барлык министрлыкларны берләштерә. Һәркайсының үз планы бар. Аларның барысы да бер ноктага – цифрлы исуллар ярдәмендә кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга барып тоташа, – диде бу җәһәттән Айрат Хәйруллин. Хезмәт күрсәтү икән, онлайн булсын, белем арттырам дисәң, мөмкинлек бирелсен, интернет һәркемгә җитсен. Тармак министры башкарган эшләрне барлады һәм башкарасыларына тукталды.

Чаралар

Цифрлаштыру елы кысасында 100дән артык чара оештырылачак. Аларның күпчелеге узды да инде. Алда – тагын да зурраклары, мөһимрәкләре һәм кызыграклары көтелә. Гомумән, бу чараларда республиканың ярты миллион кешесе катнашыр дип фаразлыйлар. Чаралар дигендә фестиваль-конкурслар, яңа төзелешләр, конференцияләр, ярышларны күздә тоталар.

Әйтик, киләсе чара инде бу атнада ук узар дип көтелә. 23 июльдә тармакның үз Олимпиадасы – «Цифровиада»сы булачак. Чара кысасында спорт уеннары да, җырбию, күңел ачулар да көтелә. Бәйрәм Казанның «Урам» паркында узачак.

– IT-компания хезмәткәрләре һәм аларның гаиләләре өчен бәйрәм бу. Татарстанда мондый формат булганы юк әле. Әйе, дәүләт хезмәткәрләре, оешмалар өчен спартакиадалар оештырыла. Без исә яңа традициягә нигез салырга булдык, – дип аңлатты Айрат Хәйруллин.

30 августта башкала халкын һәм кунакларны «Tatfure» цифрлы технологияләр фестивалено көтәләр. Бирегә мәгълүмати технологияләр тармагының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән танышырга мөмкин булачак.

21–24 сентябрь көннәрендә, традиция буенча, Kazan Digital Week халыкара форумы узачак. Чара инде Казан өчен күптәннән таныш: ул галим, эшмәкәр, IT-белгечләр, сәнәгать, бизнес вәкилләрен берләштерә.

25 сентябрьдә Татарстан Президенты Кубогына киберспорт ярышы узачак. Приз фонды – 3,5 млн сум.

Әлбәттә, Цифрлаштыру елының төп чарасы яңа «акыллы» кварталның ачылышы булыр, мөгаен. Мәгълүм булганча, ул СССРда беренче компьютерны ясаган Бәшир Рәмиев исемен йөртәчәк. IT-кварталны 30 августка өлгертәчәкләр. 49,3 мең квадрат метр мәйданда 4 меңләп яңа эш урыны, киберспорт өчен мәйданчык, конференцзал, терраса, балалар комплексы булачак. Айрат Хәйруллин искәрткәнчә, төзелеш эшләре көн-төн бара.

> Май аенда республикада 212 мең киберһөҗүмне булдырмый калдырганнар. Бу, апрель ае белән чагыштырганда, 40 тапкыр күбрәк.

Максатлар

Ел ахырына Татарстанда социаль әһәмиятле барлык социаль һәм муниципаль хезмәтләр электрон рәвештә күрсәтелә башлаячак. Хәзерге вакытта Татарстанда яшәүчеләргә барлыгы 219 дәүләт һәм муниципаль хезмәтне электрон рәвештә ала.

Калган 91 хезмәт тә ел азагына кадәр онлайн рәвешкә күчереләчәк.

Айрат Хәйруллин әйтүенчә, узган елның гыйнварына барлык хезмәтләрнең нибары 5 процентын гына электрон рәвештә алып булса, быел июнь аена әлеге күрсәткеч 70 процентка җиткән.

Бу елның алты ае эчендә Татарстан Дәүләт хезмәтләре порталы аша 72,7 мең электрон гариза тапшырылган. Баланы беренче сыйныфка кертү (30 мең), аз керемле гаиләдә тәрбияләнүче балага пособие билгеләү (11,1 мең) һәм кадастр планында җир кишәрлеге схемасын раслау (3,3 мең) буенча гаризалар бигрәк тә күп кергән.

Моннан тыш авылларны интернетлы итәсе иде. Ышанырга мөмкин хәл: халкы аз булган салаларда әле дә юк ул. Шәһәр белән авыл арасындагы бу аерманы бетерергә кирәк, ди министр. 3G һәм 4G республиканың 1336 торак пунктында юк. Ә бу җирлекләрдә республика халкының 3 проценты яши. Әлеге тигезсезлекне федераль программа кысасында хәл итәчәкләр. Җәлеп ителәчәк инвестицияләр күләме 120 млн сум булыр дип фаразлана.

Үзгәрешләр

Төзелеш эшләре – бер мәсьәлә, бу юнәлештә эшләргә теләүчеләр бармы соң? Министр, бар, ди. Бюджет урыннары саны арту һәм IT-белгечлеккә гүзәл затларның килүе – республикада тармак үсешен күрсәткән ике төп үзенчәлек.

– Республикада яшәүчеләр өчен IT юнәлештә белем алу өчен мөмкинлекләр елдан-ел арта, өстәвенә югары уку йортларында гына түгел, ә урта махсус белем бирү учреждениеләрендә дә бу мөмкин хәл. Информатика буенча имтихан тапшыручы укучылар саны да арта, – диде Айрат Хәйруллин.

Цифрлы дөнья кызларга да кызык. «Элегрәк IT юнәлешне сайлаган кызлар саны, егетләр белән чагыштырганда, 30га 70 исәбеннән булса, хәзер инде 50гә 50 дип тә әйтә алабыз», – ди министр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ КҮРСӘТЕЛӘ ТОРГАН ХЕЗМӘТЛӘР



Ел азагына республикада яшәүчеләр хезмәтләренең 60 процентыннан онлайн рәвештә файдалана алачак

Такыр юл

«Татар-информ» / Владимир Васильев

Урау юлда эшләр гөрли. М7 федераль трассасында Түбән Кама һәм Чаллыны бу калаларга кермичә генә урап узу юлында асфальт түши башладылар. Транспорт хәрәкәте ике елдан ачылыр дип көтелә. Аңа кадәр Чулман аша зур күпер төзисе дә бар.

Барлыгы өч катлам түшәлеп, гомуми калынлыгы 23 сантиметрга җиткереләчәк. «Волго-Вятскупправтодор» башлыгы Илдар Минһаҗев әйтүенчә, быел кышка кадәр юлның 10 чакрым озынлыгында ике катлам җәеп калдыру күздә тотыла. Моның өчен 118 мең тонна асфальт-бетон катнашма кирәк булачак. Түбән Кама районының Шәңгәлче авылы янындагы төзүчеләр шәһәрчеге мәйданчыгында күчмә асфальт-бетон заводы корып куелган. Юл түшәмәсе өчен катнашма шунда җитештерелә. Завод сәгатенә 240 тоннага кадәр катнашма эшләп чыгара. Төзүчеләр шәһәрчегендәге лабораториядә, грунттан алып, барлык материалларның сыйфаты тикшерелә, дип хәбәр итә «Татар-информ».

Өч этаплы эш

Биредә хәзер эшләрнең икенче этабы алып барыла. 23,7 чакрым озынлыктагы юл өлешен салуны күздә тота ул. Эшнең инде яртысы – 50 проценты башкарылган. Юл төзүчеләр графиктан алда бара.

Урау юлның бу өлешендә күперләр дә төзелә. Озынлыгы 42 метрдан 308 метрга кадәрге күперләр Алан, Келәтле, Аулаш, Аштылга, Васильев елгалары аша салыначак. Хәзерге вакытта аларның терәкләре урнаштырыла. Гомумән, икенче этапта дүрт полосалы юл, сигез күпер, ике юлүткәргеч һәм ике аслы-өсле юл төзергә кирәк булачак. Бу эшләрнең 18 миллиард 547 миллион сумга төшүе күздә тотыла.

Урау юлны төзү өч этапка бүленгән. Өченче этапта да эшкә керешкәннәр инде. Монысы озынрак – 33,5 чакрым озынлыкта. Бу өлешендә агачлар кисү, үсемлек катламын куптару эшләре алып барыла. Әлеге этапта, дүрт полосалы автомобиль юлыннан тыш, бер күпер, өч юлүткәргеч һәм ике аслы-өсле юл төзергә кирәк булачак.

Урау юлның беренче этабына килсәк, Чулман аша 1,3 чакрым озынлыктагы күпер аның төп корылмасына әйләнәчәк. Күперне Алабуга районындагы Котловка авылы тирәсендә салу күздә тотыла. Аны салу эшләре инде быел ук башланырга тиеш. Төзүчесен билгеләү өчен конкурс игълан ителгән. Оешма җитәкчесе әйтүенчә, августта контрактка кул куелса, август – сентябрь айларында әзерлек эшләрен башлап җибәрергә мөмкин булачак. Күперның гомуми бәясе 23 миллиард сум чамасы тәшкил итәргә тиеш. Тимер өлешләрен Яшел Үзәндәге Горький исемендәге заводтан сатып алу планлаштырыла.

Милекчеләр нәүмиз калмаячак

Илдар Минһаҗев күпер буенча бик күп фикерләр булганлыгын да билгеләп үтте. Иң элек аны Соколка аша салуны тәкъдим иткәннәр. Әмма, бик кыйммәткә төшүе сәбәпле, бу вариантны баш тартканнар.

Урау юлның гомуми озынлыгы 81 чакрымнан артыграк тәшкил итәчәк. Аны 2024 ел ахырына төзеп бетерү күздә тотыла. Өч этапта дүрт полосалы автомобиль юлы, барлыгы 10 күпер, аслы-өсле 6 юл, 11 юлүткәргеч төзеләчәк.

Гадәттә кайбер милекчеләрне борчымыйча гына юл салып булмый. Аны һава аша төзү мөмкин түгел чөнки. Шуңа күрә төрле максаттагы 87 җир кишәрлеген (шуның 57се – муниципаль милектә) хуҗаларыннан тулысынча яки өлешчә алырга туры киләчәк. 4 хуҗалык корылмасы, 10 йорт сүтеләчәк. Әмма милекчеләрнең барысына да базар бәясеннән компенсацияләр түләнәчәк. Юл төзегәндә агачларны да кисәргә туры килә. Әмма, Илдар Минһаҗев ышандырып әйткәнчә, киселгәннәре урынына 15 тапкыр күбрәк агач утыртылачак. Гомумән, идарә башлыгы фикеренчә, юл төзү түбәнкамалылар өчен бик отышлы булачак, чөнки ул районны үстерүгә зур этәргеч бирәчәк.

Әйтеп кенә бактым

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

«Үзеңне бел!»

Биектаудагы дачама барганда юл кырыендагы азык-төлек кибетенә керми калганым юк. Аны мин «Алсу кибете» дип йөртәм. Алсу исемле сөйкемле хатын – шул кибетнең хуҗасы. Без аның белән туганлашып беттек бугай инде.

Хәер, сүзем Алсу турында гына түгел. Әче таңнан шул кибет янында көн саен ике-өч ир кеше, бер хатын-кыз бөтерелә. Үткән-сүткән һәр кешедән йә тәмәке, йә акча сорап тора алар. Үзләре «вежливый» булырга тырышалар, «извините, у вас не будет…» дип сүз башлыйлар. Дөресен әйткәндә, тәмам гарык булдым болардан. Беркөнне оялтырга тырышып карадым: «Какие вы жалкие люди, вам не надоело клянчить!» – дидем. Ә алар: «На себя посмотри!» – диделәр, ягъни: «Үзеңне бел!» – була инде.

Ни өчен шулай дип әйттеләр икән? Бәлки, таякка таянып, аксап йөрүем мине мескен итеп күрсәтәдер. Ә алар, йөзләре зәңгәрләнеп-кызарып торса да, шактый җәһәт атлап йөриләр. Яшь буенча да миннән шактый кече.

– Нигә эшләмисез? – дип тә карыйм.

– Не твое дело, – диләр. Аларга шулай яшәү ошый, димәк.

Журналист кеше бөтен нәрсә белән кызыксынырга, төпченергә ярата бит инде ул. Баксаң, алар заманында шактый ук абруйлы кеше булганнар. Белгән кешеләр сөйләвенчә, хатын-кызы, аны Настя дип атыйк инде, яхшы гына урында эшләгән, хәтта үзенә йорт салган. Төскә-биткә дә бик чибәр иде, диделәр. Менә шул Настя баш югалтып эчә башлаган. Акчасы беткәч, 250 сумга йортын да сатып җибәргән. Ышанмадым, әлбәттә.

«250 меңгә түгелме?» – дидем. Юк, диделәр. Ушлы егетләрнең берсе Настяның махмырдан бик җәфаланган чагын туры китереп, моңа бер ярты һәм 250 сум акча биргән дә, тиешле документка кул куйдырып, йортын алган да куйган икән. Хәзер шул йорт нигезендә менә дигән коттедж тора ди.

Ә ирләрнең берсе алтын куллы слесарь булган. Акчаны да яхшы эшләгән һәм… аның нинди язмышка дучар булуын үзегез чамалыйсыз инде. Әлеге ирнең әнисе урын өстендә ята икән, әмма улы өчен әллә бар, әллә юк әлеге ана.

Җәмгыятьтәге үзгәрешләр эчүчелекне бераз киметте дә кебек, совет чорында шәһәр, район урамнарында алкашлар күбрәк очрый иде бугай. Хәзер айныткычларның булмавы (булса да бик аздыр) – шуңа дәлил. Бүген элекке кебек кеше тәрбияләү, «порукага алу»лар да юк бугай. Ихтыяр көче булган, яшисе килгән кеше хәмерне беренче урынга куймый хәзер, җәмгыятьтә табигый сайланыш бара.

Шуларны уйлап, бүгенге тормышта яхшылык табарга тырышып карыйм, әмма бик үк барып чыкмый.

Теге бәндәләрнең: «Үзеңне бел!» – дип әйткәннәре искә төшә дә якты уйлар юкка чыга. Үзен белештермичә эчкән кешеләрне, күрәсең, үзгәртеп, яңадан ясап булмыйдыр.

Элек «Аек бул – заманага лаек бул!» дигән шигарь бик популяр иде. Аның популярлыгы шул язылып куелуында гына иде бугай инде, күңелләрне яулап ала алмады ул. Хәзер шушы сүзләрне язып җәмәгать урыннарына элеп куя башласаң, бу, гомумән, көлке тоелыр иде, аеклар гына түгел, алкашлар да кычкырып көләрләр иде, валлаһи.

Бүген тагын дачага кайтам. Алсу кибетенә дә туктаячакмын. Теге «дус»ларны очратуыма да иманым камил. Алар миннән янә тәмәке яки акча сораячаклар, һәрвакыттагыча «вежливый» итеп. Әйе, тагын сораячаклар, чөнки алар мине танымаячак, бер сораган идек, дип уйламаячак, чөнки хәтерләре хәмер белән юылган. Аларны оялтырга да тырышмаячакмын, йә: «Үзеңне бел!» – дип әйтерләр тагын!

Шөкер, үземне беләм, үземә нәрсә җитми, нәрсә кирәк, йә кирәк түгел икәнен дә беләм. Шуңа күрә яшим дә. Ә алар үзләрен белмиләр, дөресрәге, белештермиләр. Кызганыч.

Ә Алсу көне буе эштә. Кибет тоту өстенә кызының баласын да, яман зәхмәт белән авыручы ирен дә карый, хәтта мөрәҗәгать иткән кешене янәшәдәге хастаханәдә эшләүче таныш табибларына да кертеп җибәрә.

Мин аннан: «Син бәхетлеме?» – дип сораган идем. «Эшли алгач, бәхетле инде», – диде.

ОЯТЛЫ КАНУН

ТЫН ҮЛЕМНЕ САЙЛАРГАМЫ, КОТЫЛУ СУКМАГЫНА БАСАРГАМЫ?

Дәүләт Думасы репрессив законнарның тулы бер сериясен штамплый һәм алар арасында берсе – әлегә кабул ителмәгән, әмма кабул ителү юлында булган бер канун проекты – зур гына резонанс таратты һәм таратачак. Сүз депутатларның бер төркеме тарафыннан кертелгән «Традицион булмаган сексуаль мөнәсәбәтләрне һәм гаилә кыйммәтләрен кире кагуны пропагандалауны тыю» дигән инициатива турында бара.

Норматив хокук актларының рәсми порталына закон проекты эленеп тә өлгермәде, мәгълүмат кырында зур шау-шу купты. «Дәүләт Думасына ЛГБТ-пропаганданы тулысынча тыю турында закон проекты керттеләр!» – дип шауладылар. «Телеграм»-каналлар үз фикерен белдерде, блогерлар үз аудиторияләрен зурайту форсатын файдаланып калырга тырышты. «Тулысынча» һәм «хәтта өлкәннәр арасында» дигән сүзләргә игътибар итик. Россиядә балалар аудиториясендә бозыклыкны тыю байтактан гамәлдә инде. Ул тыю шулай ук зур шау-шу кузгалткан вакытында, халыкара җәнҗал дәрәҗәсенә барып җитте. 2014 елның башында Нобель премиясенең 27 лауреаты, гей-пропаганда турындагы законны гамәлдән чыгаруны таләп итеп, Путинга ачык хат язды, аны британ газетасы The Independent бастырды. Хат авторлары Россияне «гейларны кысуның халыкара үзәге»нә әверелүдә гаепләделәр. Дөнья ЛГБТ-җәмәгатьчелеге яңа хокуклар яулап алганда, Россиядә балаларны бозыклыкка өйрәтү мөмкин булмау, «зәңгәр»ләргә уллыкка бала бирелмәү, аларның никахы рөхсәт ителмәү уңаеннан, «җиңгә күз яшен сөртүләр», Кремльне кешелексезлектә гаепләүләр хәттин ашты. Көнбатышның байтак кына илләрендә кече яшьтәге балаларны махсус дәресләрдә «зәңгәр»леккә һәм «алсу»лыкка өйрәтүләрен искә алсак, Россия, чынлап та, бөтенләй капма-каршы юнәлештә хәрәкәт итә.

Бер нәрсәгә тукталыйк әле: либеральлекнең һәм демократиянең төп ныгытмасы булган АКШта да егерменче гасыр ахырларына кадәр ирләрнең ирләрне сөюе тыела, «зәңгәр»ләрне психиатрларга илтәләр һәм электрошок ярдәмендә яисә баш миенә операция ясау юлы белән дөрес юлга бастырырга тырышалар иде. Дөрес, ике меңенче еллар бусагасына җиткәндә, тыю бар, әмма гамәлгә ашыру юк дәрәҗәсенә якыная башлый, «зәңгәр»ләр һәм «алсу»лар үзләренең хокуклары өчен актив көрәш җәелдерә һәм яңа меңьеллыкта инде вазгыять шулай үзгәрә: традицион булмаган ориентация вәкилләре үзләрен өстен итеп куярга керешәләр. Шундый һөнәрләр барлыкка килә: ЛГБТ-җәмәгатьчелек вәкиле булмасаң, аларда уңышка ирешү, карьера ясый алмыйсың. Нигездә сәнгать, иҗат белән бәйле тармаклар шулай үзләштерелә һәм бу гей-пропаганда өчен киң мөмкинлекләр ача. Акылдан язу өстенлек итеп тәкъдим ителә башлый, культ дәрәҗәсенә җиткерелә. Аңлашыла инде: пропаганда киңәйгән саен, «зәңгәрлек» үрчи, чөнки кеше психикасы шулай корылган: ул түбәнлеккә җиңел төшә, бозыклык йөрәккә тиз үтеп керә. Гайре табигыйлек рәсми рәвештә байрак итеп күтәрелә. Соңгы көннәрдә Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасының кешеләрнең ике җенесле генә түгеллеген рәсми рәвештә танырга җыенуы хакында белдерү таратуы кешелек җәмгыятенең «барып чыгу»ның югары стадиясенә якынлашуын хәбәр итә. Шул оешма рекомендацияләре белән дәвалан инде син, шул тәкъдим иткән даруларны файдалан.

Болар барысы да – глобальләштерү атрибутлары. Глобаль капитализм ул – матди як кына түгел, ә бар дөньяны яулап алырга омтылган идеология дә. Аның нигезендә акылын югалткан, уйлау сәләтеннән мәхрүм калган коллар тәрбияләү, процент капиталы ярдәмендә аларны кабалага төшерү, буйсынучан итеп богаулап кую ята. Юк, чылбырлар кирәкми, юләр идеяләрне массаларга сеңдерү, аларны тормыш рәвешенә әйләндерү дә җитә.

Әйдәгез, аз гына кеше табигате, аның асылы турында фикерлик әле. Адәм баласы ике җенесле итеп яратылган һәм җенесләр табигый рәвештә бер-берсенә тартылалар. Бу икенче төрле фитра дип атала, ягъни яратылыш шундый. Билгеле бер яшькә җитүгә, малайларга – кызларны, кызларга малайларны яратырга әйтеп торасы юк, хисне-омтылышны билгеле бер чикләрдә сакларга өйрәтәсе генә бар. Глобальләштерү ул чикләрне дә юарга тырыша, кеше ни теләсә, шуны эшли ала, ул – ирекле, дигән идеяне югары күтәрә, ягъни либеральлекне тормышка ашыра. Либеральлектән (ирек дигән сүздән алынган) башка җенси азгынлык та

pixabay.com

чәчәк ата алмый, гомосексуализм да масштаблы рәвештә мәйданга чыга алмый. Фитра белән табигый булмаган мөнәсәбәтләрнең конфликтын либеральлек аша гына соңгысы файдасына хәл итеп була. ЛГБТ-җәмәгатьчелек (аңа лесбиянкалар, гейлар, бисексуаллар, трансгендерлар керә) карашларының табигый түгел икәнлеген үзе дә аңлый, үзләрен – традицион булмаган мөнәсәбәт вәкилләре, безне натураллар (ягъни табигыйләр) дип йөртә. ЛГБТ идеяләре иң нык шашынган илләрдә дә кешеләрнең күпчелеге аларга тискәре мөнәсәбәттә, әмма пропаганда аларны түземле-толерант итеп тәрбияли.

Хәзер, әйдәгез, тыю мәсьәләсенә килик. Тыймасаң нишли? Ни телисәләр, шуны кыланасыннар әйдә, дип уйлап карыйк. Эш шунда: процент капиталы глобаль икътисадны әчтән кимергән һәм җимергән кебек үк, традицион булмаган җенси мөнәсәбәтләр дә җәмгыятьне һәлакәткә алып бара. Бозыклык киң таралып, иң югары ноктасына җитүгә, котылгысыз рәвештә катаклизмнар башлана. «Содом» һәм «Гоморра» дигән сүзләрне ишеткәнегез бардыр, хыял җимеше генә түгел алар, чынлыкта Лут кавеменең (беренче гомосексуалистлар җәмгыятенең) һәлак ителгән урыннары. Вулкан көле астында калган Помпейда да җенси бозыклык киң таралуын дәлилләгән фактлар җитәрлек.

Бүгенге Лут кавеменең дәвамчылары да үзләре белән һәлакәт ияртеп йөртәләр. Танылган Америка психологы, Гаиләне тикшерүләр институтына нигез салган галим Пол Кэмеронга сүз бирик әле. «Көнбатыш туучыларның түбән дәрәҗәсе аркасында тын гына үлеп бара. Һәм тууларның аз булуы нәкъ менә ЛГБТ хәрәкәтенә бәйле. Әгәр дә ЛГБТ вәкилләре тиз артса, без акрын гына сүнеп барудан чыга алмаячакбыз. Алар бала тапмыйлар гына түгел, ә җәмгыятькә кыйммәткә дә төшәләр. Бу мохиттәге өлкәннәр дә, үсмерләр дә башка халыкка караганда табибларга ешрак мөрәҗәгать итә. Бу җенси инфекцияләр таралу һәм психологик проблемаларга бәйле – гейлар һәм лесбиянкалар депрессияләргә ешрак бирелә, үз-үзләрен үтерү ягына нык авышалар. Һәм, ниһаять, алар арасында наркотик бәйлелеккә төшүчеләр дә күбрәк…» Кэмеронның шушы сүзләре генә дә ЛГБТ-пропаганданы тоталь рәвештә тыярга җитәрлек. Алар традицион булмаган җенси мөнәсәбәтләрнең кеше психикасын ни рәвешле гарипләндерүен һәм җимерүен аңларлык. Әмма «зәңгәрлек» ул «зәңгәр»ләр проблемасы гына түгел, җәмгыятьнең һәлакәте, зур катастрофасы да аларга бәйләнгән. Безнең үзен зыялы дип атаган катлауда традицион булмаган мөнәсәбәт вәкилләренә нигездә түземле мөнәсәбәт формалашкан, «теләгәч, шулай яшәсеннәр» дигән фикер өстенлек алган. «Бары тик бер нәрсәгә генә ачу килә: алар үзләрен өстен итеп тотарга тырышалар», – дип, социаль челтәрләрдә язган каләм ияләрен очраткан бар. Әмма эш алай гади генә түгел шул. Бозыклык үзен сугышчан һәм һөҗүмчән итеп тотарга ярата, халыкара җәмәгатьчелеккә һәм оешмаларга апелляция ясый. Шундый шартларда депутатлар зыянлы пропаганданы тыярга җыена икән, моңа ник борчылырга?

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

БУ КЕШЕГӘ НӘРСӘ ҖИТМИ?

Бер яктан, замананы сүгәрлек сәбәпләр дә юк шикелле. Эшле-ашлы, җитеш тормышта яшибез. Вакыт-вакыт дусишләр белән очрашырга җай чыга, күңел тарткан эш белән шөгыльләнергә мөмкинлекләр җитәрлек. Ризык дисәң, табын тулы, киям дисәң, киемнең дә ниндие генә юк. Тирә-юньдә дә бары яхшы кешеләр генә кебек. Тик...

Илдар Мөхәммәтҗанов

Җан тынычлыгын, яшәү ямен урлый торган вакыйгалар да җитәрлек. Әллә аларны үзебез уйлап чыгарабызмы? Хәсрәткә түзеп була, рәхәткә чыдап кара дигәннәре шушымы? Тормышның артык җитеш булуы, җиңеллеккә омтылу кешене, киресенчә, артык иркәләп җибәрмиме икән?

Безне бу хакта сүз башларга соңгы арада җәмгыятьтә күзәтелгән әхлаксыз, куркыныч, кысадан чыккан гамәлләр этәрде. Кешенең үз-үзенә һәм үз ишенә карата кылган золымнары турында еш ишетергә туры килә. Моны табигый күренеш дип кабул итеп булмый һәм ярамыйдыр да. Цивилизация алга киткән саен кешенең тормышка карашы кирегә тәгәрәргә тиеш түгелдер ләбаса.

Ай уртасында Казанның Петербург урамындагы бер ташландык йортта ике яшүсмер кызның үз-үзләренә кул салырга омтылулары турында хәбәр чыкты. Сәбәбе – җавапсыз мәхәббәт. Кызганыч, кызларның берсе асылынып үлә, берсе исән кала. Өстәвенә балалар бу гамәлләрен телефоннарына төшереп, интернетка да урнаштыра. «Зур» буласы килү телəгеме, кемгәдер нидер исбат итүме, әллә «лайк» артыннан куумы – кызлар артыннан сүз йөртү булмасын, сәбәпләрен үзләре генә беләдер. Тик моның кадәр кара кайгыга китерерлек булдымы икән соң ул сәбәп? Хыяллары, матур киләчәккә өметләре бер дә булмаганмы икәнни?

Тискәре хисләрне йөгәнли алмау нәтиҗәсендә Санкт-Петербургта да бер фаҗига килеп чыга. 28 яшьлек ир-ат, ярсуын тыя алмыйча, кечкенә кызының башын идәнгә бәреп үтерә. Соңыннан ул хатынының да «котыла». Бу явызлыкларыннан соң, берни булмагандай, хатынының туганнары белән телефон аша аралашуын дәвам иттерә әле. Билгеле, аны хокук саклау органнары тоткарлый. Иртәме-соңмы җәзасын да алыр инде ул. Әмма намус дигәне белән нишләргә? Әллә золым кылганда уянмаган бу хис соңыннан да уянмасмы?

Көн саен булмаса да, еш булып тора торган очракларның икесе генә әле бу. Һәркайсы да җәмгыятьне бер мизгелгә уятып ала, тетрәтә торганнардан. Әйтик, кызлар очрагында тәрбия җитмәүгә сылтаучылар күп булды. Социаль челтәрләрдә аеруча әтиләрнең тәрбия мәсьәләсеннән читләшә баруына төрттерделәр. Балаларның шөгыльсез һәм хезмәт тәрбиясеннән башка үсүенә дә ишарә ясаучылар булды.

Икенче очракта исә хәзерге заман кешесенең психикасы никадәр тотрыксыз булуына гаҗәпләнделәр. Әмма, психика тотрыксыз дип, бөтен кеше дә пычакка үрелсенме хәзер? Үз-үзең белән килешә алмаудан бүтәннәр зарар күрергә тиешме?

Практик психолог, психология фәннәре магистры Зөһрә КӘРИМОВА белән адәм баласының тормыштан ни өчен ваз кичүе, кешегә бер бирелгән гомерне матур итеп үткәрергә нәрсә җитмәве турында сөйләштек.

Ни өчен кеше тормыштан канәгать түгел?

Ничек кенә яңгырамасын, тормыштан канәгать булмау хисе кешеләрнең үзләре теләгәнчә яшәмәүләреннән килеп чыга. Уйлап карасаң, аларга берәү дә турыдан-туры «шулай яшәргә тиеш түгел син» дип богау салмый бит. Чикләүләр – үзебездә.

Тагын бер сәбәбе – кеше үзе телəгән нәрсәләрне артккы планга чигерә. Һәм шулай дөрес, шулай кирәк дип саный. Канәгатьсезлек хисе тормышның өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга куркудан да барлыкка килә.

Корбан булып калу җиңелрәк, башкаларны, җәмгыятьне гаепләү күпкә уңайлырак бит. Эшендә уңышка ирешү, хыялларны чынбарлык итү, хоббига вакыт бирү өчен үзеңә дә күп көч куясы бит югыйсә.

Җәмгыять авырумы? Кешеләргә ни җитми?

Күп кенә суицид очракларының сәбәбе – кешенең үзенә терәк-таяныч таба алмавында, минемчә. Ул үзен башкалар тарафыннан аңлау тапмаган, ишетелмәгән итеп тоя, шуннан курка, үз җилкәсендә мәшәкатьләрен күтәрә алмастайга әйләнә. Максаты, тормышка карата мәхәббәте булмаганга, кешенең үзенә ышанычы да югала.

Җәмгыять авыру дип әйтеп булмый. Бу очракта җәмгыятьтәге кешеләрне сәламәт түгел дияргә мөмкин. Төгәлрәк әйткәндә, фикерләү рәвешебез. Без яхшы нәрсә урынына начарын сайлыйбыз. Безгә хәсрәтләнү, ничек кенә яңгырамасын, кызыграк, рәхәтрәк. Ә бит гомер бер генә. Шуны аңларга иде. Һәркем сайлау алдында тора: яратып, тулы канлы тормыш белән яшәргәме, әллә инде кайгырып, елап кына ятаргамы? Монда сайлап та торасы юк кебек инде.

Түбәнкелеккә бирелүчеләр күп. Сәбәбе?

Мин кабул итә торган кешеләрнең дә күпчелегендә шул проблема. Депрессиягә бирелүнең сәбәпләре берничә була ала. Кемгәдер аралашу җитми, кемдер ялгызы гына калырга күнекмәгән, кемдер гел үз уйларына батып йөри, әмма берни дә эшләми. Берүзе генә калган кеше еш кына «мин берәүгә дә кирәк түгел инде» дип, үз-үзен авыр уйларга күмәргә тотына.

Түбәнкелеккә бирелүчеләрнең күплегеен тагын шуның белән дә аңлатырга була: күпләрнең шөгыле, кызыксынуы, яратып йөри торган урыннары юк.

Мин үзем – позитив кеше, кешеләргә мәрхәмәтле. Төрле бәхәс-низагларга керергә яратмыйм. Синең кәеф юк икән, ул башкаларның кәефен дә бетерергә кирәк дигән сүз түгел бит әле. Кеше белән аралаша белмисең икән, бу сыйфат таләп ителгән җирдә эшләргә, булырга кирәкми. Башкаларны хөрмәт итегез, шул очракта йөрәктә мәхәббәт тә булыр.

Битарафлык артты кебек. Кешеләргә хас асыл сыйфатлар югала...

Битарафлык дигәннән, монда әле икеләнергә була. Мин психологик уеннар уздырганда киресен күзәтәм. Кешеләргә ярату (иң элек – үзеңне) хисен кайтарырга тырышам. Дөньяда моннан башка булмый.

Әлбәттә, башкаларга карата битараф булган кешеләр дә юк түгел инде. Әмма бу мәрхәмәтлелек, киң күңеллелек кебек сыйфатлар булмаганлыктан түгел бит. Гади генә әйтсәк, бу – кешенең саклану битлеге. Ул башкаларга якын килмәскә һәм бүтәннәрне дә сиңа якын китермәскә булыша, «куркыныч» дөньядан саклый. Әмма бу бит кешенең эчке киртәләре (установка) генә, яши-яши туплаган тәҗрибәбез генә. Балачактан ук, болай итмә, моңа ышанма, монда куркыныч, тегеләй ярамас, дип сеңдереп киләләр. Асылда, кеше кечергән барлык гыйбрәтләр дә үзеңне яратырга һәм башкаларга ышанырга өйрәтергә тиеш.

Үсмерләргә ни җитми? Бик күпләре яшьли яшәп туя...

Яшүсмерләр үзләрен яратмый. Аларга шул җитми. Таяныч һәм ышаныч тапмыйлар. Шулай ук алар үзләрен ишеттерергә һәм тыңлаганнарын тели.

Алар бит менә ничек уйлый: бер проблема белән очрашалар да, бетте – дөнья кителде. Алга таба тагын да начаррак, куркынычрак булачак. Проблеманы хәл итү, анализлау юк.

Үз-үзләрен ярату да җитми, дидек. Әгәр дә яратсалар, үзләренә карата ниндидер золым ясарлар идеме соң? Яраткач, андый нәрсәләр эшлисе килми ул.

Яшүсмерләрнең начар шөгыльгә вакыты аз калсын өчен, билгеле бер мавыгулары, максатлары булырга тиеш. Булган очракта, алар бернинди куркыныч бәйлелек корбанына әверелмәс. Яңа, онытылмас хисләр, яңа тойгылар бүләк итә торган чаралар, мөмкинлекләр бихисап. Төрле иҗади түгәрәкләр бар. Баларны шунда бирергә кирәк. Шулай ук үзара сөйләшү, фикерләшеп тору мөһим. Баланың нәрсә турында уйлавы белән кызыксынып торырга кирәк. Гомумән, яшь аң гел нәрсә беләндер мәшгуль булса яхшы.

ТОРМЫШКА МӘХӘББӘТНЕ НӘРСӘ КАЙТАРА АЛА?

1 Тотрыклы режим, физик активлык һәм сәламәт туклану.

2 Табигать белән дус булу. Әйтик, еш кына паркта йөрү, өйдә яшелек үстерү, мини-бакча булдыру, агач утырту.

3 Максат кую. Күп очракта «мин шулай эшләргә хыялланам» дию генә аз. Менә шушыңа илтә торган кечкенә адымнарны да фаразларга, шуңа атларга да кирәк. Ягъни юл картасын булдырырга.

4 Булганын кадерләү. Тагын да кәттәрәк телефон, машина турында хыялланганчы, кемдәдер анысы да юк бит, дип уйлап кую да җитә. Матди әйберләрне тормыш мәгънәсе итүдән сакланыйк.

5 Шатлана белү хисе. Зәңгәр күк, кояш баешы, үләндәге чык, кошлар сайравы, дулкыннар уйнавы – шуларга карау да тормыштан канәгать булу хисен тоярга булышырга тиеш.

6 Чиста һава, кояш һәм чиста су.

КАЗАН КҮЧТӘНӘЧЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Экскурсовод Гүзәл ГЫЙМАТДИНОВАдан Казанның 5 үзенчәлекле урыны:



- Казан Кремле;
- Милли китапханә;
- Кабан күле яр буе;
- Иске Татар бистәсе;
- Казансу елгасы буенча катерда сәяхәт.

ШӘҺӘР БУЙЛАП ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ЭКСКУРСИЯЛӘР

➤*«Казан университеты табышмаклары»*
Экскурсия дәвамында университет тарихы, аның фәнни мәктәпләре, бөек галимнәрнең исемнәре һәм аларның ачышлары белән танышырга, XIX гасыр университеты мохитен тоярга мөмкин.

➤*«Казанның бакчалары»*
Шәһәрнең иң яшел урыннары буйлап экскурсия бу. Эрмитаж, Лядской, Ленин бакчалары, Черек күл, 1000 еллык скверы һәм башка паркларның тарихы, алар белән бәйле тарихи вакыйгалар – барысын да сөйләячәкләр.

➤*«Борынгы Казан әкиятләре» (балалар өчен)*
Балаларны шәһәр белән әкиятләр аша таныштырачаклар. Казан Песие, Зилант, Шүрәле, Камыр Батыр – экскурсиянең төп геройлары.

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кесәләрнең калыны кирәк

Күптән түгел Татарстан башкаласында Россиянең туризм бизнесы вәкилләре чит ил туристларын җәлеп итү турында сүз куертты. «Күпфакторлы үзгәрешләр шартларында Россиянең кунакханә бизнесы» дип аталган конференция кысасында булды бу сөйләшү. Ни өчен чит ил туристларына аерым игътибар биргәннәр икән, диярсез. Конференциядә катнашучылар, өйдә утырткан пандемия чорыннан соң уңай якка үзгәрешләр булса да, Россия халкы гына туризм тармагын саклап кала алмаячак, дип борчыла.

Моның сәбәпләре берничә икән. Беренчедән, Россия халкы бер барган шәһәренә икенче мәртәбә юл тотмый, ди белгечләр. Өстәвенә кунакта да әллә ни озак тормыйлар. Икенчедән, чит ил кунаклары белән чагыштырганда, безнекеләрнең кесәләре дә юкарак. Россиянең туризм тармагына озаклап кунак була торган, калын кесәле чит ил туристлары гына ярдәм итә алачак, янәсе. Конференция барышында әнә шундый фикергә килделәр.

Татарстанның Туристик агентлыклары ассоциациясе президенты Рамил Мифтахов та тышкы туризмны үстерергә кирәк дигән фикердә.

– Берничә ел элек Европадан килгән туристларның саны бик күп иде. Алманнар, французлар, итальяннар Россиягә, аерым алганда, Казанга еш килде. Хәзер хәлләр башкачарак. Чит ил кешеләре сирәк кунак була. Башта пандемия, хәзер сәяси кризис... Бездә диңгез булмаса да, күрсәтерлек урыннарыбыз җитәрлек. Миңа калса, дәүләт ярдәменә таянып, тышкы туризм үсешенең яңа стратегиясен тормышка ашырсак, чит ил вәкилләрен янә җәлеп итеп булачак, – дип сөйләде ул.

> **Сан**
>
> Быел Казанга килүче туристлар саны пандемиягә кадәрге чор – 2019 ел күрсәткеченә җитәргә мөмкин. Ул чагында Татарстан башкаласында 3,5 миллион сәяхәтче булып киткән. Шәһәрнең Туризмны үстерү комитеты директоры Дарья Санникова шулай дип белдергән. «Май бәйрәмнәрендә туристлар ташкыны 30 процентка артып, 200 мең кешегә җитте. Казанга ял көннәрендә генә түгел, гаиләләр, балалар белән иркенләп тә киләләр», – дигән ул.

Үзебезнекеләр дә җитә

Ләкин чит илдән туристлар килми дип, Казанның буш торганы юк бит. Җәй башыннан бирле туристлар иң күп җыела торган урын – Бауман урамында алма түгел, чия төшәрлек урын да күренми. Татарстан башкаласы буйлап экскурсия уздыручылар да туристларның күп булуына сөенә. Хәер, кыска гына экскурсияләрнең дә бәясе 500 сумнан башланганны исәпкә алсаң, сөенмәү гөнаһ булыр иде.

Гид Динә Латыйпова сүзләренчә, быел Казанга килүчеләр арасында Брянск һәм Курск өлкәләреннән Бурятиягә кадәр кунаклар бар.

– Елдагыча, Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Екатеринбургтан кунаклар күп. Иң кызыгы: пандемиягә кадәр төньяк башкаладан сирәк киләләр иде. Ә чит илләрдән килүчеләр аз быел. Инглиз телендә дә экскурсияләр уздырам, андые быел әле бер генә тапкыр булды, – дип сөйләде ул безгә. – Җәй көне туристлар Казан буйлап җәяү йөрергә ярата. Иң яраткан урыннары – Казан Кремле, Иске Татар бистәсе. Башкаладан тыш, Зөя утрау-шәһәрчеге дә бик популяр туристлар арасында. Экскурсия азагында алардан Казан турында сорашам. Күпчелеге шәһәрнең чиста-пөхтәлеген, матурлыгын, кунакчыллыгын мактап туя алмый. Кол Шәрифне күрер өчен генә дә киләләр безгә. Кимчелекле яклардан, Идел буйлап елга сәфәрләре булмауны атыйлар.

Казанны кыйммәтле шәһәр дип атаучылар сирәк, ди Динә. Алай да, бездәге бәяләрне Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан калышмый, диючеләр юк түгел икән.

«Татар-тур» компаниясе җитәкчесе Оксана Әхмәтҗанова Казанга килүче кунакларны гомумиләштереп, бүгенге турист «портреты»н төзеп күрсәтте:

> **Бу – кызык!**
>
> «OneTwoTrip» сервисы белгечләре Россия халкы тиз арада җыенып чыгып китәргә әзер булган шәһәрләрне барлаган. Беренче урында – Мәскәү (40 процент), аннан Санкт-Петербург (12 процент), Екатеринбург (6,6 процент), Казан (4,6 процент), Сочи (3,4 процент).

– Аңа – 35–50 яшь. Казанга ул икенче яки өченче мәртәбә килә. Гаиләсен яки дусларын да алып килгән. Аның кереме яхшы, шуңа күрә ул яхшы отельдә яши, экскурсияләрнең дә бер кешелеген генә ала. Аңа һичшиксез татарларның милли ризыкларын татып карарга, иң тәмле чәкчәк сатыла торган кибеттән күчтәнәч һәм Казан турында искә төшереп торачак сувенир алырга кирәк. Мондый кунак бары тик таксида гына йөри. Гидка да «чәйгә» дип бирәр мең сум акча бирә, – диде Оксана.

Ул да туристларның Казанны чисталыгы өчен мактауларын әйтте.

– Туристлар да үзгәрә. Әйтик, тарих белән дә ныграк кызыксыналар. Музейларга еш йөриләр. Борынгы биналарны күзләп кенә дә көннәрен уздырырга мөмкин алар. Билгеле, аларга милли төсмерләрне дә күрсәтергә тырышабыз. Моның белән акча эшләүчеләр дә җитәрлек бит бездә. Татар халкының танылган көн эшләнмәләре турында сөйлибез дә алар сатыла торган кибетләргә кереррә тәкъдим итәбез. Казан көмеше турында сөйләгәч, күп кенә туташ-ханымнар үзләренә һәм күчтәнәчкә алкалар сатып ала.

Казанны бер күргәч, тагын киләсе килә. Гид Екатерина Веселовцевага туристлардан бу сүзләрне еш ишетергә туры килә икән.

– Кунаклар арасында урта һәм югары керемлеләр күбрәк. Эшмәкәрләр, бизнес өлкәсендә эшләүчеләр еш килә. Тәҗрибәле сәяхәтчеләр Казанны Европа белән чагыштырырга ярата. Ә чит илдән кунакларны күрмим диярлек. Ләкин аңа карап кына эшләүдән туктаган юк. Бер үк кешеләр белән әллә ничәшәр мәртәбә очрашам – гашыйк булып китәләр, кире әйләнеп кайталар Казанга, – ди ул.

Кунак сүзе

Туристлар үзләре нәрсә ди соң? Бауман урамына чыгып аралаштык әле үзләре белән.

Мәскәүдән Филипповлар гаиләсе Казанга ике баласы белән килгән. «Балалар белән булгач, ялыбыз кыйммәткәрәк чыга. Иң күп чыгым тору һәм ашауга китә. Ләкин Казан үз бәясен каплый ул. Мондагы милли кухняны яраттык, ризыклары бик тәмле. Шәһәрнең архитектурасы бик ошый. Диңгез буендагы ялны яратмаган кешегә менә дигән. Ләкин җәй көне барыбер суга тартыласың. Су коена торган урыннар аз икән монда», – дип сөйләде гаилә башлыгы.

Саратовтан Вадим Краевка бездәге кунакчыллык ошаган. «Кая гына барсаң да, туристларга мөнәсәбәт бик яхшы. Аңлаталар, өйрәтәләр. Минем беренче генә килүем, ләкин тагын кунак булырмын дип уйлыйм. Дусларым белән ял иттек, кичке Казанга гашыйк булдык. Шәһәр яп-якты, мондагы утлар – могҗиза инде менә. Өч көн ял иттек, иртәгә кайтып китәбез. Ял бик кыйммәткә төшмәде, чөнки күбесенчә шәһәр белән таныштык. Күчтәнәчләр җыя башлагач, ашау өчен акча шактый тотылды инде – анысы сер түгел», – ди ул.

Читкә чыгу кыйммәткәрәк төшү аркасында Россия шәһәрләре буйлап сәфәр чыккан Юлия белән Дмитрий Казанны Мәскәү һәм Санкт-Петербург белән чагыштыра. «Монда бәяләр түбәнрәк дип уйлаган идек, ялгышканбыз икән. Ләкин алдан әзерләнеп, планлаштырып килсәң, кесәң артык каерылмый. Шәһәрнең архитектурасы искиткеч, монда шулкадәр чиста, ризыклар шундый тәмле. Татар халык ашларына гашыйк булдык. Бәяләре дә «тешләми» аларның. Кыйммәтле рестораннарга йөрмәдек, үзәк урамнардагы милли кафеларда ашадык. Сувенир кибетләренә керергә тырышмыйбыз, анда акчаны күп калдырырга туры киләчәк. Берәр рецепт өйрәнеп кайтуың хәерлерәктер моннан», – ди Юлия.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

29 июльдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Гөлгенә ШИҺАПОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Автокибет кайчан килә башлар?

Безнең авылда ике кибет бар иде, әмма яптылар. Дөрес, бер эшмәкәр килеп, продукция сатып йөри. Әмма ул үзе кайчан тели, шунда килә. Җитмәсә, продукциясе дә искергән була. Татарстанда кечкенә авылларга автокибетләр йөрүен беләбез. Безгә автокибет кайчан килә башлар икән?

Балык Бистәсе районы
Казаклар Чаллысы авылы халкы

Айрат Хәкимуллин, Балык Бистәсе районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары:
– Безгә ипине Мамадыштан китерсеннәр дип, авыл халкы үзе сорады бит. Шуннан соң ике кибет хуҗасы да: «Читтән товар китерү безгә табыш бирми», – дип, зарын белдерде. Көндәшлек булгач, ябылабыз, дигәннәр иде. Утка, газга түләргә кирәк. Бу авылда бер сәүдә ноктасы ябылды, тик шәхси кибет эшли. Хәзер менә автолавка сорыйлар. Без каршы түгел. Әгәр авыл халкы сораса, хәл итәрбез. Әлегә бер мөрәҗәгать тә килмәде.

Эштән китсәң, пенсия артамы?

Белүебезчә, эшләүче пенсионерга, хезмәт урыныннан киткәч, эшләгән чорындагы индексацияләрдән чыгып, пенсия күбрәк күләмдә түләнә башлый. Пенсиясе артканнан соң кабат эшкә керә икән, аның күләме инде кимеми. Әмма соңгы вакытларда, эшләгән вакыттагы индексацияләр исәпкә алынмаячак икән, дигән сүзләр йөри башлады. Ягъни пенсионер эшеннән туктаса да, пенсиясе шул ук күләмдә калачак. Дөрес сүзме бу?

Фәнисә ХӘЙРЕТДИНОВА. Казан

Россия Пенсия фондының Татарстандагы бүлеге:
– Чыннан да, гамәлдәге кануннар нигезендә, хезмәт эшчәнлеген туктаткан пенсионер, эшләгән чорындагы барлык индексацияләрне исәпкә алып, акчаны арттырылган күләмдә ала башлый. Эштән туктаучыларның пенсиясенә бу өстәмә, эштән китеп, өч ай узгач (дүртенчесендә) бирелә. Бу эш болайрак башкарыла. Эштән киткәннән соң икенче айда пенсионерның элекке эш бирүчесе аның эштән китүе турында Россия Пенсия фондына мәгълүматлар (СЗВ-М формасы буенча хисап алынуга) тапшыра. Аннан соң киләсе айда Пенсия фонды пенсияне барлык индексацияләрдән (пенсия күләмен арттырудан) чыгып исәпли. Ә инде эштән китүенең өченче аенда пенсионерга пенсиясе өстәмә белән, ягъни эшләгән вакытындагы барлык арттырулардан чыгып исәпләнә.

Сезне борчыган имеш-мимешләргә килсәк, Пенсия фондында аларны дәлилләүче бер документ та юк.

Йорт салу өчен күпме агач бирелә?

Йорт салучылар үз гомерендә бер мәртәбә күпмедер күләмдә арзан бәядән агач әзерли ала дип ишеткән идек. Аны алу тәртибен аңлата алмасызмы икән?

Наил МӨХЕТДИНОВ. Балтач

Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгы:
– Татарстан законы нигезендә 25 елга бер тапкыр йорт һәм каралты-кура төзү өчен – 100 куб. метрга кадәр, 10 елга бер тапкыр йортны һәм каралты-кураларны төзекләндерү өчен 50 куб. метрга кадәр агач әзерләргә рөхсәт ителә.

Татарстан Президентының 2015 елның 11 декабрендәге Указы белән Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгының «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу турында шартнамәләр төзү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты расланды. Хезмәттән файдалану өчен, министрлыкка гариза һәм шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык тапшырырга кирәк. Документларны өйдән чыкмыйча, Россия дәүләт хезмәтләре күрсәтү порталы яки Татарстан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша бирергә була.

Агач бүлеп бирүгә карата нинди дә булса ташламалар каралмаган. Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча агач бәясе Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 7 октябрендәге карары нигезендә исәпләп чыгарыла.


Илдар Мөхәммәтҗанов

Тәкъдим

МИЛЛИ КИЕМНӘР ХАТЫН-КЫЗНЫ КҮРКӘМ ИТӘ

Һәр милләтнең үз теле, гореф-гадәтләре булган кебек милли киемнәре дә бар. Татар халкының милли киемнәре бик күркәм. Ләкин хәзерге җәмгыятьтә хатын-кызларның ирләр киемнәре киеп йөрүе гадәти күренешкә әйләнде, хәтта кайбер дин тотучы хатын-кызлар да чалбар киюдән тартынмый. Бер дә матур күренеш дип санамыйм. Ә ул сәхнәләрдә чыгыш ясаучылар, телевидениедә чакырылучыларның киемнәре турында әйтәсе дә юк. Милли кием бөтенләй онытылып бара. Шуның белән хатын-кызларның сөйкемлелеге, энке матурлыгы да югала дип уйлыйм. Шул хакта уйласыннар иде.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА. Казан

Балалар мәйданчыгында ут булырмы?

2020 елда Октябрьнең 65 еллыгы урамындагы 6 нчы йортның ишегалдын төзекләндереп, балалар мәйданчыгы ясаганнар иде. Тик баганада һаман ут юк. Аны кайчан куярлар икән?

Райлә ДУДКО. Балык Бистәсе районы

Марс Мәгыйзов, Балык Бистәсе районы башкарма комитеты җитәкчесе:
– Ишегалдын төзекләндерү, балалар мәйданчыгын булдыру республика программасы буенча башкарылды. Менә шушы вакытта: «Нинди тәкъдимнәрегез бар?» – дип, монда яшәүчеләрнең фикерләрен белештек. Гадәттә җыелышларга актив берничә кеше йөри. Калганнарның исе китми. Аннан тәзелеп беткәч, тегесе яки монысы кирәк, бу җирдә караңгы, яктылык җитеп бетми, дип шалтырата яки шикаять яза башлыйлар. Беренчедән, җыелышларга йөрсеннәр иде. Без бит аны кызык өчен генә оештырмыйбыз. Икенчедән, мондый эшләрне бюджеттагы акчага карап, алдан планлаштырабыз. Ут мәсьәләсенә килгәндә, әлеге проблема хакында беләбез. Акча табылу белән, август – сентябрь айларында баганаларга утлар куярга җыенабыз.

Россия почтасы көненә бирелә торган акчам кая киткән?

Мин почтада 1968 елда эшли башлаган идем. Бу өлкәдә 1995 елга кадәр хезмәт куйдым. Ул вакытта авыр букчаларны күтәреп, биш чакрым җәяү кайта идек. Кайткач, газета-журналларны таратырга кирәк. Эшләгән вакытта ай саен премия бирәләр иде. Хезмәтемне бәяләделәр, исемем Мактау такталарына язылды. Үткән елга кадәр бәйрәмдә бирелә торган акчаны алдым. Быел өч почтаны бер итеп, яңа хуҗа куйгач, миннән стаж сорый башладылар. Кая куйган алар минем стажны? Стажым – 18 ел. Кемнең моңа эче пошкан икән? Россия почтасы көненә бирелә торган 500 сум акча кая киткән? Хөрмәтле редакция, сездән төгәл җавап көтәм.

С.Х. МИҢНУЛЛИНА.
Кама Тамагы районы Чаллы авылы

«Россия почтасы» җәмгыятенең Идел төбәге матбугат хезмәте:
– Чыннан да, озак еллар эшләгән элеккеге хат ташучыларга Россия почтасы көненә шундый түләүләр каралган. С.Х. Миңнуллинага, паспорт һәм ИНН (булган очракта) кебек документларын алып, Буа почтамтына барырга кирәк. Моннан тыш, стаж турындагы мәгълүматны раслау өчен, хезмәт кенәгәсенең күчермәсен дә сораячаклар. Кирәкле документларны тапшырган очракта хезмәттәшебез түләүне алачак. Бу түләүне алу өчен минималь стажга таләпләрне үзгәртмәдек.

Кирәкле медицина җиһазын нигә бирмиләр?

Туры эчәккә операция ясаткан идем. Бүлеп чыгару функциясе бозылганга, моңа кадәр өч айга бер мәртәбә калоприемник бирәләр иде. Ноябрь аенда бирелми башлады, ләкин аннан башка булмый. Бу җиһазны кайчан китерә башларлар икән?

Фәһим ГАЗИЗОВ. Минзәлә районы

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан буенча төбәк бүлеге матбугат үзәге:
– Газизов Ф.Н. узган елның 16 сентябреннән декабренә кадәр кирәкле булган әйберләр белән тәэмин ителгән. 2022 елның 18 гыйнварында төбәк бүлеге «Медека» оешмасы белән дәүләт контракты төзеде. Тик әлеге товарларның саны чикле булган һәм запаста да калмаган. Шуңа бәйле рәвештә, товар китерүчегә товар күләмен 10 процентка арттыру тәкъдиме белән хат юлланды. Тик «Медека» оешмасының товарны арттыруга өстәмә килешү төзү мөмкинлеге булмаган. Шуңа күрә кайбер кешеләр тәэмин ителмичә калган. 3 нче кварталда килешү төзү планлаштырыла. Газизовны контрольгә алдык, кирәкле әйберләр кайту белән тәэмин ителәчәк.

Мәсьәләне хәл итүнең тагын бер юлы да бар. Инвалид техник тернәкләндерү чарасын үз акчасына сатып алган очракта аңа компенсация түләнә. Моның өчен товарны сатып алганнан соң, аның бәясен каплау өчен, Дәүләт контракты фондының төбәк бүлегенә гариза тапшырырга кирәк. Шуннан соң компенсация күләме билгеләнә. Ул товарны сатып алганлыкны раслаучы чектагы суммага туры килмәскә дә мөмкин.

Уеннар үткәрелергә тиештер бит?

Кызым «Салават Күпере» торак комплексындагы балалар бакчасына йөри. Үзебезнең тәрбиячеләребез җәйге ялга киткәч, ике төркемне бергә куштылар. Шул вакыттан бирле бала: «Апа безнең белән шөгыльләнми, телефонында утыра», – дип зарлана. Кич аны алырга килгәндә, үзем дә күрдем. Балалар бакчасы өчен түләү үзгәрмәде. Шуңа күрә тәрбияви чаралар, уеннар да үткәрелергә тиештер ләбаса. Тәрбиячеләргә балаларны карап торганнары өчен генә түләмиләрдер бит?

Лилия ГАЙНУЛЛИНА. Казан

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат үзәге:
– Уку елыннан аермалы буларак, җәйге чорда саф һава сулау вакыты озайтыла, күңел ачулар күбрәк планлаштырыла, уеннарга күбрәк вакыт бирелә. Бу очракны төгәлрәк ачыклау өчен, бакчаның номерын күрсәтүегезне сорыйбыз.

Инвалидлык кәгазен ничек ясатырга?

Мин – III төркем инвалид. Күптән түгел инвалидлык кәгазен югалттым. Еракларга барып йөри алмыйм шул. Аны кабат ничек ясатырга мөмкин?

Исемем редакция өчен генә.
Буа районы

Нурия Вәлиева, Татарстан буенча медицина-социаль экспертизалар бюросы табибы, белешмәләр бирүче консультант:
– Мондый хәлгә юлыгучылар өчен гариза тапшыруның берничә юлы бар. Җитәкче исеменә электрон почта, «Россия почтасы» аша хат җибәрергә мөмкин. Казанда Мәҗит Гафури, 71а й. адресы буенча урнашкан төп бюрога килергә мөмкин. Чаллы, Әлмәт һәм башка шәһәрләрдәге үзәкләргә барырга була. Буада исә 23 нче бюробыз (телефоны: 88437433146) бар. Әлеге ханыма шунда барып, гариза язарга тәкъдим итәбез. Паспорт, СНИЛС, әгәр инвалидлык кәгазенең күчермәсе сакланган булса, шушы язу кирәк. Булмаса, безнең белгечләр Пенсия фонды аша белешәчәк. Инвалидлык кәгазе озак әзерләнми, иясенә почта аша җибәреләчәк.

Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

25 июль | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10, 02.15 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ» 12+
10.00, 23.20 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ» 12+
11.00 «Татар халык җырлары» 0+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.30 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Ком сәгате» 12+
14.00 «Ландшафтный дизайн – это просто» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00, 03.30 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.00 «Реальная экономика» 12+
00.10 «Семь дней +» Эльмира Калимуллина 12+
00.35 «Каравай». Народное искусство Лимы Кустабаевой 6+
01.00 «Семь дней +» Мансур Гилязов 12+
01.25 «Таяну ноктасы» 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 Г.Кариев. «АРТИСТ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
11.00. 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Ихсан күңел». Шагыйрә Илсөяр Иксанова турында телеочерк 6+
15.30 «Ватандашлар» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 16.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Телеканал «Доброе утро»
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.35 Информационный канал 16+
12.00 Новости с субтитрами
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости с субтитрами
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости с субтитрами
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «ОТЧИМ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.45 «Большая игра» 16+
00.40 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьевым» 12+
22.40 «МАРИУПОЛЬ». Фильм Андрея Медведева 16+
23.40 «Вечер с Владимиром Соловьевым» 12+
00.50 Мария Андреева, Евгений Цыганов, Надежда Маркина, Петр Зайченко и Борис Невзоров. «СОФИЯ» 16+
01.50 Екатерина Кузнецова, Владимир Жеребцов, Леонид Громов, Александр Самойленко, Екатерина Васильева и Борис Галкин. «КОРОЛЕВА БАНДИТОВ» 12+
03.40 «ЖЕНЩИНЫ НА ГРАНИ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.10, 12.30, 14.50 Новости
06.05, 19.30, 23.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.15, 12.35, 02.40 Специальный репортаж 12+
09.35, 00.45 «Рок-н-ролл под Кремлем» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55. 14.55 «ПОБЕГ» 16+
15.50 «Громко». Прямой эфир
16.40 «Игры дружбы-2022». Плавание. Прямая трансляция из Казани
19.55 Футбол. «МЕЛБЕТ – Первая Лига». «КАМАЗ» (Набережные Челны) – «СКА-Хабаровск». Прямая трансляция
22.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция
00.15 Тотальный футбол 12+
03.00 Новости 0+
03.05 «Человек из футбола» 12+
03.35 Регби. PARI Чемпионат России. «Динамо» (Москва) – «Химик» (Дзержинск) 0+
05.20 «Громко» 12+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.50 «ВОКАЛЬНО-КРИМИНАЛЬНЫЙ АНСАМБЛЬ» (S) 16+
21.45 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ» (S) 16+
00.00 «ПЕС» (S) 16+
01.55 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведемся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Ношеная одежда» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.40 «ТРИ ИСТОРИИ ЛЮБВИ» 16+
19.00 «КАК ДОЛГО Я ТЕБЯ ЖДАЛА» 16+
22.55 «Порча» 16+
23.30 «Знахарка» 16+
00.00 «Верну любимого» 16+
00.30 «Понять. Простить» 16+
01.20 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.55 «Тест на отцовство» 16+
04.35 «Давай разведемся!» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.00 «УЧАСТОК ЛЕЙТЕНАНТА КАЧУРЫ» 16+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.25 «ОПАСНЫЕ ГАСТРОЛИ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «ТУЛЬСКИЙ-ТОКАРЕВ» 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Подводная война». Док. сериал «П-1» 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Берлинский сюрприз Сталина» 12+
22.55 «ГЛАВНЫЙ КОНСТРУКТОР» 12+
01.20 «СВИДЕТЕЛЬСТВО О БЕДНОСТИ» 12+
02.25 «ВОР» 16+
04.05 «БЛИЗНЕЦЫ» 6+

26 июль | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10, 02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ» 12+
10.00, 23.00 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ» 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплете» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00, 21.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Без химии». Док. фильм 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Хамид Муштари. Человек-загадка 12+
00.40 «Каравай». Поэзия русского костюма 6+
01.05 «Уроки истории». Татарское общество в XVIII веке 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00. 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 16.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Илтани Илялова турында телеочерк 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Телеканал «Доброе утро»
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.35 Информационный канал 16+
12.00 Новости с субтитрами
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости с субтитрами
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости с субтитрами
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «ОТЧИМ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.45 «Большая игра» 16+
00.40 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьевым» 12+
23.55 Мария Андреева, Евгений Цыганов, Надежда Маркина, Петр Зайченко и Борис Невзоров. «СОФИЯ» 16+
01.05 Екатерина Кузнецова, Владимир Жеребцов, Леонид Громов, Александр Самойленко, Екатерина Васильева и Борис Галкин. «КОРОЛЕВА БАНДИТОВ» 12+
02.50 «ЖЕНЩИНЫ НА ГРАНИ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.10, 12.35, 14.55, 17.10, 21.45 Новости
06.05, 16.40, 21.00, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.15, 12.40, 02.40 Специальный репортаж 12+
09.35, 00.45 «Рок-н-ролл под Кремлем» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.00 «ПОБЕГ» 16+
15.55 Футбол. Обзор тура 0+
17.15, 04.00 «Игры дружбы-2022». Прыжки в воду. Прямая трансляция из Казани
19.10 Бокс. Командный Кубок России. Прямая трансляция
21.50 Футбол. Чемпионат Европы-2022. Женщины. Прямая трансляция
03.00 Новости 0+
03.05 «Правила игры» 12+
03.35 «Катар-2022» 12+
05.00 Бокс. Командный Кубок России 0+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.50 «ВОКАЛЬНО-КРИМИНАЛЬНЫЙ АНСАМБЛЬ» (S) 16+
21.45 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ» (S) 16+
00.00 «ПЕС» (S) 16+
01.55 «АЛИБИ» НА ДВОИХ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведемся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
12.05 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Игрушечная собачка» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «СПИСОК ЖЕЛАНИЙ» 16+
19.00 «КАК ДОЛГО Я ТЕБЯ ЖДАЛА» 16+
22.55 «Порча» 16+
23.30 «Знахарка» 16+
00.00 «Верну любимого» 16+
00.30 «Понять. Простить» 16+
01.20 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.55 «Тест на отцовство» 16+
04.35 «Давай разведемся!» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.30. 14.05 «ТУЛЬСКИЙ-ТОКАРЕВ» 16+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20 «ДОБРОВОЛЬЦЫ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.25, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.50 «Подводная война». Док. сериал. «С-4» 16+
19.40 «Улика из прошлого». «Запах хищника. Брежнев против маньяка» 16+
22.55 «ИЗ ЖИЗНИ НАЧАЛЬНИКА УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА» 12+
00.35 «ИХ ЗНАЛИ ТОЛЬКО В ЛИЦО» 12+
02.05 «ГЛАВНЫЙ КОНСТРУКТОР» 12+
04.15 «ОПАСНЫЕ ГАСТРОЛИ» 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 25–31 ИЮЛЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Бу атнада эштә яки тормышта «ялтырап» алу өчен искиткеч шәп мөмкинлекләр чыгачак. Иң элек гаделлекне торгызуга бәйле булыр сымак бу. Берочтан файдалы элемтәләр дә корылачак.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Ниндидер бер эчке каршылык катгый гына бер карарга килергә комачаулар. Тирәгездәге хәйләкәрләр шул икеле-микелерәк халәтегездән файдаланып калырга маташыр. Сак булыгыз шундыйлардан!

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Гаиләдә үзара мөнәсәбәтләрдә хата китәргә мөмкин. Гел сез генә хаклы була алмыйсыз, башкаларны да тыңлагыз. Дөньяны шулай гына көйләп булачак.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Дәүләт оешмаларына эше төшүчеләр әйбәт нәтиҗәгә ирешәчәк. Акча ишелеп керәчәк. Чираттагы ялны кайда уздырырга, дип аптырап йөрүчеләргә искиткеч әйбәт мөмкинлекләр пәйда булачак.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Өйдә ремонт эшләрен башлап җибәрү өчен акчасы да, башкасы да табылачак. Гомумән, бу атна акчалы булачак һәм бик файдалы узачак. Якын дустыгыздан бер сер ишетү сәеррәк фикерләргә китерер.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Уңайлы чор. Бигрәк тә ялгыз Кызлар өчен! Аларның тормышында үтә матур романтик мөнәсәбәтләр башланып китәргә мөмкин. Кайбер озын теллеләрнең гайбәтенә карамыйча, алга барыгыз!

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Өйдә дә, эштә дә баш булып, бөтен җаваплылыкны үз өстегезгә алырсыз. Бик дөрес: уңышка ирешү өчен нәкъ менә шулай – кыю һәм әрсез булырга кирәк хәзер. Атна ахырында узгандагы матур истәлекләргә бирелеп алырга туры килер.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Бер танышыгыз күптәннән көтелгән яңалык әйтеп куандырыр. Үзегезгә кагылышы әллә ни булмаса да, кирәк әйбер ул... Кайчандыр нык дулкынландырып, соңыннан онытылган бер вакыйганың нечкәлекләрен белеп алу үз бәягезне бик дөрес аңлауга китерер.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Күп еллар буе күңелегезгә тынгылык бирмәгән бер мәсьәләгә, ниһаять, саллы гына нокта куелыр. Эшегездә дә куанычлы хәлләр булып алыр. Мәсәлән, әйбәт кенә премиягә өметләнә аласыз.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Эленке-салынкы гына эшлисе түгел: җитәкчегез моны бик тиз сизеп алып, тиешле нәтиҗә чыгарырга мөмкин. Изге урын буш тормый, дигән гыйбарәсе дә бар бит... Үзегездән яшерелеп килгән бер әйбер турында ишетеп, хәйран калырсыз.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Бу атнада песи кебек кенә йөрүең хәерлерәк. Җитәкчегезнең күзенә бик күренмәскә, акыллыга сабышып, теге яки бу бәхәскә кермәскә, килделе-киттеле киңәш белән кешенең башын бутамаска, дигәнрәк сүз бу. Сәбәбеме?..

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Нәрсәнедер үзгәртергә маташмагыз: сәеррәк кенә түгел, күңелсезрәк тә тәмамланырга мөмкин. Аның каравы мөнәсәбәтләрне тәртипкә салу өчен әйбәт кенә җае чыгар. Сәламәтлек тә, ниһаять, борчымый башлар.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Түбән Кама «Нефтехим» гавами акционерлык җәмгыятенең олигомерлар һәм гликольләр заводы баш механигы төркеменең ремонт буенча әйдәп баручы инженеры **Зарипова** Валентина Семеновна; В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең нефть һәм нефть продуктларын сату идарәсе бүлеге җитәкчесе **Баһаутдинова** Луиза Марс кызы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлары өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Энергетика өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Сетевая компания» акционерлык җәмгыятенең «Әлмәт электр челтәрләре» филиалы директоры **Латыйпов** Гамир Мәгъсүмҗан улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары **Алиуллов** Айрат Җәүдәт улына; Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының матбугат хезмәте әйдәүче белгече **Әскәрова** Тәнзилә Зиннәт кызына; Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары **Рогожкин** Максим Анатольевичка; «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесенең җитәкче-урманчысы урынбасары **Вахтерова** Татьяна Николаевнага; Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Алабуга районы һәм Алабуга шәһәре территориаль бүлекчәсе экспертиза бүлеге башлыгы **Нуриева** Чулпан Фәвасим кызына; Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районындагы Социаль яклау идарәсе башлыгы **Романова** Светлана Александровнага; Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медицина-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесенең 5 номерлы эксперт составы медицина-социаль экспертиза буенча табибы **Садретдинова** Вәсилә Корбан кызына; **«Буа шикәре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына; «Майский» теплица комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына**; **«Нармонка» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына**; **«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Сувар» газетасы редакциясе» филиалы коллективына**; Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Вафин** Рамис Рөстәм улына; «Эбиволь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Забегина** Татьяна Вениаминовнага; «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы» дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмасы адвокаты **Карпов** Сергей Александровичка; «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы» дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмасы адвокаты **Петров** Андрей Олеговичка; «Нурлат район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең ветеринария табибы – ветеринария-санитария экспертизасы лабораториясе мөдире **Кузнецова** Светлана Николаевнага; «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 10 номерлы онкология бүлекчәсе табиб-онкологы **Кутовой** Иван Борисовичка; Чуашстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән дини оешмасы каршындагы Чуашстан Республикасы Комсомол районы Урмай авылының Рәхимулла исемендәге 5 номерлы мөселман мәхәлләсе җирле дини оешмасы рәисе, имам-хатыйбы **Минаҗетдинов** Хәмидулла Рәхимулла улына; «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Яшел Үзән» мәгълүмат үзәге» филиалы чыгарылыш мөхәррире **Шәрәфиева** Венера Мансур кызына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

И АЯГЫМ, ТҮЗ ГЕНӘ!

Кан тамырлары киңәю, аяклар шешенү җәй көне күпләрне борчый. Челләдә нәкъ менә шушы чирләр баш калкыта, ди белгечләр. Аларны алдан кисәтеп буламы? Варикоз, аяк шешенүдән йорт шартларында котылу мөмкинме?

Сорауларга 7 нче номерлы шәһәр хастаханәсе табиб-хирургы, флеболог Ирек ШӘРИПОВ ачыклык кертте.

:: Ни өчен җәй көне аяк шешенү, варикоз очраклары ешрак күзәтелә?
– Эсседә кан куерып китә, шуңа күрә аяклар шешенә. Бу чорда тромбофлебит, тромбоз кебек кан тамыры авырулары да ешрак очрый. Шуңа күрә кан тамырлары киңәйгән (варикоз) кешеләргә кояш астында озак йөрергә ярамый. Кояшта кызыну да киңәш ителми. Моннан тыш компрессион оек та киеп йөрергә кирәк.

:: Варикоз, иң беренче чиратта, кемнәргә яный?
– Нәселендә кан тамырлары киңәю чиреннән интегүчеләр булган кешегә, озак утырып яки озак басып эшләүчеләргә үз сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк. Аларда варикоз килеп чыгу ихтималы бик зур.

:: Кан тамырлары киңәю, аяклар шешенүдән өй шартларында гына котылып буламы?
– Кызганыч, котылып булмый. Кисәк кенә шешенгән очракта «ашыгыч ярдәм» чакырырга яки табиб-флебологка, кан тамырлары хирургына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Шешенү күптәннән күзәтелгән, кан тамырлары чыгып торган очракта табибка планлы рәвештә язылырга киңәш ителә. Аңа кадәр аякка компрессион оек киеп йөрергә кирәк. Аякларны өскә күтәреп ятып тору, контраст душ керү дә файдага булачак. Кояшта кызынырга, эссе мунча, ваннага керергә ярамаганын да онытмагыз.

:: Җәйге эсседә шешенү, кан тамыры киңәю очракларын алдан кисәтеп буламы?
– Аларны алдан кисәтеп булмый. Ник дигәндә, варикоз вакытында клапаннар «ватылган» булып санала. Аларны исә операция яки компрессион оек ярдәмендә генә «төзәтеп» була. Кан тамырлары чыгып торган, вак кан тамырларыннан аягында «йолдызчыклар» хасил булган кешеләргә бакчада эшләгәндә сак булырга кирәк. Кояш астында озак йөрергә, авыр күтәрергә ярамый. Эсседә кыен булса да, шул ук компрессион оекны да салырга киңәш ителми. Иң яхшы профилактика чарасы ул. Ял итәргә барганда, озак вакыт очкычта очканда, машинада барганда йөреп алырга, аякларны күтәребрәк торырга кирәк.

:: Алда телгә алынган унайсызлыклардан котылу өчен, гимнастика, махсус күнегүләр бармы?
– Эштә озак итеп утырып торырга туры килә икән, аякларның очына басабыз да табанга төшәбез. Бу күнегүне басып та, утырып та эшләп була.

:: Нәрсә ашавыбыз йогынты ясыймы?
– Алдарак әйткәнемчә, 99 процент очракта варикоз нәселдән күчә. Ул авыр күтәрү аркасында, бала тапканда да килеп чыгарга мөмкин. Шуңа күрә бу очракта нәрсә ашавыбыз әллә ни зур йогынты ясамый. Шешенүне булдырмау өчен исә тозлы ризыкны азрак ашарга, төнгә таба су эчмәскә кирәк. Виноград, йөзем дә файдалы. Ләкин файдасы тисен өчен, аны бер йөк машинасы күләмендә ашарга кирәк булыр иде. Шунысы мөһим: рационда файдалы матдәләр, витаминнар һәм микроэлементлар да булырга тиеш.

pixabay.com

Исеңдә тот!

Җиләге дә, яфрагы да файдалы

Кура җиләге салицил кислотасына бай. Ул ялкынсынуларга каршы көрәшә, тән температурасын төшерә.

- Салкын тигәндә, кура җиләге белән чәй эчәргә киңәш ителә. 2 аш кашыгы җиләкне 3\4 стакан кайнар суда 15–20 минут төнәтергә, сөзәргә кирәк. Төнәтмәне кайнар килеш көнгә 2–3 мәртәбә икешәр стакан эчәсе. Ютәл булганда, төнәтмә ярдәмендә ингаляция ясарга мөмкин. Аны кайнатып чыгарып, баштан сөлге белән капланып, шуның парын суларга кирәк. Процедураны көнгә 2–3 тапкыр һәм йоклар алдыннан ясау әйбәт.

- Тамак төбе авыртса, кура җиләге серкәсе белән чайкарга киңәш ителә. 2 стакан җиләкне 2 стакан алма серкәсенә салып, 10 көн җылы урында төнәткәч, сөзеп, стерильләштерелгән банкага тутыралар. Төнәтмәне суыткычта саклыйлар.
- Тонзиллит кискенләшсә, авыз эчен кура җиләге согы белән чайкатырга кирәк. Аны көнгә өч мәртәбә кабатлыйсы. Кура җиләге согы авыртуны баса, шешне бетерә.
- Кура җиләге хатын-кызлар өчен файдалы. Ул кан агуны туктата, күрем вакытында авыртуны киметә. Йөкле хатыннарга да чама хисен онытмыйча, кура җиләге ашарга киңәш ителә. Бу җиләк фолий кислотасы, тимергә бай. Ул карында бала дөрес үссен, анемия булмасын өчен кирәк. Кура җиләгеннән ясалган морс, компот йөклелекнең беренче аенда токсикозны бетерә, эч кибүдән саклый.
- Кура җиләге яман шеш күзәнәкләренә үсәргә ирек бирми.
- Гипертония булганда, тигез күләмдә кура җиләге белән яфрагын алып, 2 аш кашыгы күләмендә 1,5 стакан кайнар суга салалар. Сүлпән утта 4–5 минут кайнаткач, 1 сәгать төнәтеп, сөзәргә кирәк. Төнәтмәне ашарга ярты сәгать кала, көнгә ике-өч мәртәбә 1–2 стакан эчәсе. Кура җиләге инфаркт, инсульт кичергән кешеләргә дә файдалы.
- Баш авыртса, дару эчкәнче, 1әр стакан кура җиләге ашарга киңәш ителә.
- Кура җиләге А витаминына бай, күрүне яхшырта, тиренең картаю процессын акрынайта. Организм яхшырак эшкәртсен өчен, аны эремчек яки каймак белән ашарга киңәш итәләр.

Белеп тор!

БӘРӘҢГЕ СОГЫ ШИФАЛЫ

✓Бәрәңге согында иммунитетны яхшырта торган С витамины бар.
✓Икегә аерылган юка чәчләрне бәрәңге согы белән дәвалыйлар. Аны чәч төбенә сөртеп, 20 минут тотыгыз да юып төшерегез.
✓Коры бит тиресен бәрәңге согына манылган мамык белән дымландырыгыз.
✓Бәрәңге согы йөрәк өчен дә файдалы, ул холестерин күләмен киметә.
✓Гастрит вакытында бәрәңге согын ун көн эчеп, ун көн тәнәфес ясарга кирәк. Иртәнге ашка кадәр ярты сәгать алдан бер стакан эчәргә киңәш ителә.
✓Бәрәңге согы бавырны һәм үт куыгын агулы матдәләрдән чистарта.
✓Аны еш эчкәндә, ашказаны-эчәклек тракты эшчәнлеге дә яхшыра.
✓Бәрәңге суын көнгә 3 мәртәбә ашар алдыннан эчсәң, файдасы зур. Тик ул 10 минут эчендә бозыла. Аны сыгу белән эчәргә кирәк. 4–5 атнада ул – гастрит, колит авыруларын, 6–8 атнада ашказаны җәрәхәтен бетерә. Яшь бәрәңге согы аеруча файдалы. Тәмле булсын өчен, аңа бал йә мүк җиләге согы кушарга мөмкин.

Кәһвә гомерне озайта

Озак яшим дисәң, көненә ике чокыр кәһвә эч! Америка галимнәре шундый ачыш ясаган. Алар 700 мең кешенең сәламәтлеген өйрәнгәннән соң: «Кәһвә ир-ат һәм хатын-кызларның гомерен кыскартучы чирләр килеп чыгу ихтималын киметә», – дип нәтиҗә ясаган. Моннан тыш көнгә берничә чокыр кәһвә эчкән кеше күңел төшенкелегенә дә сирәк бирешә икән. Галимнәр бу эчемлекнең картлык чорында еш күзәтелгән Паркинсон, Альцгеймер авыруларын кисәтүен дә ачыклаган.

Горчица тамак авыртудан коткара

Тамак авыртканда бер чәй кашыгы тозга бераз гына лимон согы, бер чәй кашыгы бал, ярты чәй кашыгы горчица һәм 100 мл җылы су салабыз. Шуның белән көнгә берничә тапкыр тамакны чайкатабыз. Гайморит булганда, томау төшкәндә, тукыма кисәген кайнар суга манып алып, аңа коры горчица салабыз да борынга куеп торабыз.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

ҮЗЕ ШАРДАЙ, ТӘМЕ БАЛДАЙМЫ?

Җәйге эсселәр җитүгә, күңел үзеннән-үзе карбызга тартыла. Сусауны басудан тыш, бик күп файдалы үзлекләргә ия булган бакча сыен сайлаганда истә тотарга кирәкле киңәшләр турында карбыз сатучы Омар Сәитов сөйләде.

Тавышын тыңла

Карбыз сайлаганда, аңа суккалап карарга кирәк. Әгәр тавышы тонык кына килә икән, димәк, әле ул өлгереп җитмәгән. Тавышын чагыштыру өчен, төрле зурлыктагы берничә карбызның «тавыш»ын тыңлап, яңгыравыгын сатып алыгыз.

Өлгергәне кабыгыннан күренә

Өлгергән карбызның кабыгы кара яшел төстә һәм бик тыгыз була, аны тырнап карау да мөмкин түгел. Әгәр кабыгында бәрелгән, киселгән, изелгән һәм бераз чери башлаган урыннар булса, аны алмавың хәерле. Әгәр карбызның бер өлеше кара яшел, бер өлеше ачык яшел булса да, бу аның тулысынча өлгереп җитмәве турында сөйли. Яхшы дигән карбызның кабыгындагы бизәкләре дә тонык булмый. Аның кабыгында җирдә ятканнан барлыкка килгән җете сары табы да булырга тиеш. Әлеге табы тонык кына булса, димәк, карбыз әле өлгереп җитмәгән дигән сүз.

Зурына кызыкма

Авырлыгы 10 килограммнан арткан карбыз сатып алырга тырышмагыз. Авыррак булган саен тәмлерәк дигән сүзләр дөрес түгел. Чамадан тыш зур карбыз өлгереп җитмәгән һәм химикатлар белән үстерелгән булырга мөмкин. Иң татлы һәм сусыл карбызның авырлыгы 6–10 кг чамасы. Өлгергән карбызның эче ярмаланып тора, аның тыгызлыгы да җитлекмәгәнгә караганда көпшәргәк сыман, шунлыктан ул җиңелрәк тә була.

Тикшереп кара

Карбызның өлгергәнме-юкмы икәнлеген аны суга салып карап белеп була. Әгәр суда батмый икән, димәк, ул өлгергән. Ә батса, әле ул өлгереп җитмәгән дигән сүз. Карбыз зурлыгына карата җиңелрәк тоелса, курыкмый сайлый аласыз, ул өлгергән.

Бал кортлары яраткан

Яхшы карбызның тышында җөйле хәтерләткән серкәләнү урыны булырга тиеш. Аның мондый матур булмаган билгесенә шикләнеп карарга кирәкми. Бу бал кортлары аны яраткан, үз иткән дигән сүз, димәк, мондый җиләк татлы булачак.

Койрыгы кипкән булсын

Карбызның формасы түгәрәк һәм овал рәвешендә була. Гадәттә, түгәрәге татлырак була, диләр. Чынлыкта, карбыз сортларын аера белсәгез, озынчалары арасында да татлыларын табарга була. Иң мөһиме: карбызның койрыгына карарга онытмагыз, ул кипкән булса, өлгергән дигән сүз.

Йомшагы ялтырамасын

Карбыз эченең төсе аның сорты һәм кайда үсүенә дә бәйле. Өлгергән карбызның эче ярмаланып җемелдәп тора һәм сусыл була. Әгәр карбыз кисеп җибәргәннән соң шома һәм ялтырап тора икән, бу аның өлгереп бетмәвен яки бөтенләй бозылып әчи башлавын аңлата.

m24.ru

Иң популяр карбыз сортлары

Ультраранний, Соренто, Сибирский гигант, Огонек, Настик, Оранжевый король, Розовое шампанское, Подарок северу, Атаманский, Медовик, Сладкий бриллиант, Фотон.



Роспотребнадзор киңәш итә

Карбызны юл буеннан сатып алмагыз. Алар тиешле тикшерү үтмәгән булып, авыр металл һәм тузан сеңдергән булырга мөмкин. Таләпләргә туры килгән карбызның куркынычсыз булуы турындагы тулы пакет документлары була, сатып алганда аны күрсәтүләрен таләп итә аласыз. Моннан тыш аның махсус стеллажларда кояш нуры төшмәслек урыннарда саклануына да игътибар итегез. Карбызлар кояшта җирдә аунап ятарга тиеш түгел.

Карбызны кисәр алдыннан, аның тышын сабынлы җылы суда юып алыгыз. Бу аны микроб һәм бактерияләрдән арындыру өчен кирәк.

Иң татлы, сусыл һәм куркынычсыз булган карбызларны июль ахырында һәм августта ашап калырга ашыгыгыз.

Бакчачыга

КӘБЕСТӘНЕ КОТКАРАБЫЗ

Кәбестәне корткычлардан коткару буенча бакчачы блогер **Рәмзия Әхмәдуллина** киңәшләрен бирде.

▸ 5 л суга 40 г нашатырь спирты, 2 аш кашыгы сыек сабын кушып, яфраклары юешләнерлек итеп сибеп чыгарга.

▸ 3 л суга бер савыт даруханәдә сатыла торган валерьянка, бер аш кашыгы сыек сабын кушып, яхшылап болгатып сибәргә. Әлеге эшләрне кич яки иртән башкарырга кирәк. Чөнки кызу кояш яктысында тукландырырга да, корткычларны агуларга да ярамый.

Тәмле булсын!

ҖИР ҖИЛӘГЕННӘН КАЙНАТМА

Алсу Хәкимова рецепты

Быел җиләк баллы булганлыктан, шикәр комын бер кг җиләккә 800 гр исәбеннән генә салып ясадым. Кайнатманы кайнап чыкканнан соң, акрын утта 3 минут кайнатып алам да сүндерәм. 2 сәгать чамасы суынганнан соң, кабат 2–3 минут кайнатып алам. Шул рәвешле өч мәртәбә эшлим. Аннары кайнар килеш стерильләштерелгән банкаларга тутырып, тимер капкач белән каплап куям. Болай эшләгәндә кайнатманың төсе матур, кызгылт була.

КЫРЛЫГАН ЧӘЕ

Зөлфирә Гәрәева рецепты

Кырлыган (иван-чай) яфракларын банкага төеп тутырырга. Аннары өч көн тәрәзә төбендә кояшта тоткач, иттарткычның эре тишекләсеннән чыгарырга. Чыгарылган яфракларны яхшылап уганнан соң, 8 сәгать дымлы чүпрәк каплап тотарга һәм коры тукымага җәеп, төнгә калдырырга кирәк. Икенче көнне 100 градуска кадәр җылытылган газ мичендә ишеген бераз ачык калдырып киптерергә. Бик мәшәкатьле чәй ясау, тик аның искиткеч исеннән соң барысы да онытыла.

Киңәш-табыш

Агын сайлаган уңар

✓ Юыну бүлмәсенә плитканың аксыл төстәгесен сайласагыз оттырмассыз, чөнки чәчрәгән су тамчылары анда күренми диярлек. Ә менә караңгы төстәге плиткаларны чиста тоту шактый кыенга туры киләчәк.

✓ Кечкенә бүлмәләр өчен караңгы төстәге плиткалар сайламагыз. Чөнки ул бүлмәне тагын да таррак һәм кечкенәрәк күрсәтәчәк.

✓ Ачык төстәгесе зур һәм кечкенә бүлмәләр өчен дә яхшы булачак.

✓ Панно һәм декоратив плиткалар куллану юыну бүлмәсен зуррак күрсәтә.

✓ Юыну бүлмәсендә караңгы төсләр һәм глянец куллану затлылык өсти. Тик аны бик аз күләмдә, чама белеп кенә кулланырга кирәк.

Үзем сынадым

ГЛАДИОЛУСЫМ ШАУ ЧӘЧӘК

Гладиолуслар күп һәм матур итеп чәчәк атсын өчен, мин бер ысул кулланам. 10 граммлы бер пакет бор кислотасын бераз гына җылы су салып болгатам, аннары аны 10 литр суга салам. Түтәлгә башта су сибәм, аннары һәрбер чәчәкнең төбенә әлеге катнашманы сибеп чыгам. Болай эшләгәндә, гладиолус чәчәкләре бик эре, матур була, чәчәк атка та тиз генә коелмый, озак тора.

Г. НИЗАМОВА. Мамадыш

ГӨНАҺЛАРНЫҢ НИГЕЗЕ – КАЛЕБ ЧИРЛӘРЕ

Дүрт аяклы ат та абынганны, туры юлдан атлап барган инсанга да хаталану хас, билгеле. Бу тормышта берәү дә гөнаһсыз түгел. Шулай да, гөнаһ кылганыңны белеп, вакыт узганнан соң тәүбәгә килергә, тормышны ак биттән башларга соң түгел. Гөнаһның нинди төрләре бар? Гөнаһларың турында башкаларга сөйләргә ярыймы? Тәүбәгә килүне нәрсәдән башларга?

Лаеш районындагы «Ихлас» мәчете имамы Мөдәррис ГЫЙМРАНОВ белән шушы һәм башка сорауларга җавап эзләдек.

:: Гөнаһның нинди төрләре бар?

– Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! Әссәламугаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Җәмгыять, кешелек дөньясын камилләштерү өчен шәригать кануннары, динебез бар. Болар һич кенә дә безнең тормышны авырайту өчен түгел! Гөнаһлардан арындырып, дөньялыкта да, ахирәттә дә уңышка ирешү, бәхетле булу өчен бирелгән алар. Гомумән, дин нәрсәгә кирәк? Гади генә итеп әйтсәк, дин – Аллаһы Тәгалә белән аның мәхлукларын бәйләп торган юл. Дин юлы – Аллаһы Тәгалә юлы. Фәкать дин генә, Аллаһы Тәгаләнең шәригате генә кешене аңа якынайта.

Конституция, төрле кодекслар, төрле дәрәҗәдәге канунар бар бит. Берсе берсеннән өстен булган кебек, динебездә дә фарыз, ваҗиб, ике төрле мәкруһ, ике төрле сөннәт һәм башка гамәлләр бар. Шуннан чыгып, гөнаһлар да, гамәленә карата, төрле була. Әйтик, эшләсәң дә, эшләмәсәң дә, яраклы гамәлләр бар, зур, кече гөнаһлар билгеле, әдәпсез гамәлләр бар.

:: Гөнаһсыз кеше юк инде ул. Әмма соңгы арада аларның иң куркынычларын кылучылар арта. Моны ничек аңлатырга?

– Рәсүлебез (с.г.в.) хәдисендә: «Һәр адәм баласы ялгышучан. Әмма ялгышканның да иң хәерлесе – тәүбә кылучысы, гафу үтенә һәм итә белүчесе», – ди. Гөнаһсыз кеше юк.

Соңгы арада иң куркыныч гөнаһларны кылучылар арта баруга килгәндә, бу адәм баласының нәфесе, гыйлемсезлеге, шайтан коткысына бирелүенә бәйле. Динебезгә, Коръәнгә, галимнәр сүзенә карасак, гөнаһ кылуның ике сәбәбе бар. Беренчесе – нәфескә иярү, икенчесе – тәкәбберлек.

Аллаһы Тәгалә атабыз Адәмне бар кылгач, бөтен күк әһелләренә сәҗдә кылырга, баш иярга куша бит. Бер шайтан гына үзен яхшы санап, тәкәбберлек күрсәтеп, баш имәгән. «Мин аннан хәерлерәк», – дип уйлаган. Атабыз Адәм белән анабыз Һаваның, нәфесләренә алданып, җимештән авыз итүләрен беләбез.

Дөньядагы гөнаһларның асылында адәм баласының җан-калебендәге авырулары, чирләре ята. Матди дөнья турында гына уйлау, шул хакта гына фикер йөртү, ахирәт турында оныту, курыкмау, динсезлек, намуссызлык, оятсызлык үз җимешен бирә. Бүген кылынган гөнаһ җәмгыятьтә, киләчәктә зур бер шеш булып калкып чыгачак.

:: Мин гөнаһлы инде, монда да, тегендә дә тәмуг миңа дип, үзгәрергә теләмәгән, нәрсәне дә булса үзгәртеп булганын белмәүчеләр, өметсезлеккә бирелүчеләр була. Зиначы, карак, кеше үтерүчеләрнең гөнаһы туры юлга басканда кичереләме?

– Теләмәүчеләр белән белмәүчеләр арасында зур аерма бар. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Үзләренә үзләре зыян салып, гөнаһ кылган колларыма әйт! Беркайчан да Аллаһның рәхмәтеннән өметләрен өзмәсеннәр!»

Теләмәүчеләр ник теләми? Белепме, белмичәме? Аның сәбәпләре бар бит. Аллаһның рәхмәтеннән өмет өзү, икеләнү – үзе үк гөнаһ. Аллаһы Тәгалә кичерми дип уйларга ярамый! «Минем колымның гөнаһлары җир белән күк арасын тутырса да, мин аны кичерәм», – диелә бер хәдистә.

Зиначы, карак, кеше үтерүчеләрнең гөнаһы да, димәк, туры юлга бассалар, кичерелә дигән сүз.

Нинди гөнаһлар кичерелми? Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә: «Аллаһы Тәгалә

vk.com

үзенә тиңдәшлек кылуны гафу итми, тиңдәшлек кылудан башка гөнаһларны үзе теләгән кешегә гафу итә».

:: Зур җинаять кылмасалар да, кеше тормышын бутап, сүз йөртеп, тәүбә итмәүчеләр зур гөнаһ кылганнардан өстенрәк саналамы?

– Кеше тормышын бутау, сүз йөртү зур гөнаһлардан санала. Сүз йөртү – аеруча яман нәрсә. Ул – кабер газабына бер сәбәп. Сүз йөртү туганнарны талаштыра, дусларны дошманлаштыра, кабиләләрне пычак тотарга этәрә.

:: Гөнаһлар кичерелсен өчен нишләргә?

– Нинди гөнаһ кылганыңа карап. Әйтик, кайбер әдәпсез гамәлләребез өчен «әстәгъфируллаһ, кичер, Раббым» дип әйтү дә җитә. Зуррак кимчелек икән, ике рәкәгать тәүбә намазын укырга, кылган гөнаһың өчен үкенергә һәм башка аны кабатламаска вәгъдә итәргә кирәк. Бөтен җаның-тәнең белән шуңа омтылырга! Кимчелек кылдың икән, җомгага бар. Сәдака бирү, кешегә ярдәм итү дә хәерле. Аллаһы Тәгалә үз рәхмәтен кеше рәхмәтенә яшергән. Намаз уку да гөнаһлардан чистарта. Зикер әйтү, догалар уку – менә күпме мөмкинлек.

– Отличникның психологиясе башка. Аңа гел «5»ле генә кирәк, «4ле» өчен дә бик нык борчыла. Үземнең кызыма да: «Бу әле чик түгел, алда «3ле»се дә, «4ле»се дә булыр, тормыш бер төрле генә бармый», – дип аңлата идем. Укучыларга да шуны төшендерәбез, – ди директор. – «Отличник» гел үрнәк булырга, алда барырга тырыша. Үзенең бала икәнен дә оныта. Шуңа күрә кабат сынауны бер дә кирәк дип тапмыйм. Мәктәп коллективына ышанырга кирәк. «5ле»гә генә укыган балага медальне бернинди имтихансыз бирсеннәр. «Медальне акламыйлар», – дип сөйләү белән дә килешмим. Алар болай да борчыла. Гаиләсе дә, укытучысы да хафалана. Моны фаҗигагә тиңләргә кирәкми. Ярар, булмаган икән, булмаган. Укырга керер, тормышта үз урынын табар, әллә нинди дәрәҗәләргә ирешер. Мәгариф өлкәсендә 50 ел эшлим. Һәрвакыт тикшерү, контроль, бәяләү һәм чагыштыру. Бу бер дә дөрес түгел. Моны гади авыл укытучысы буларак әйтәм.

Медаль ияләренең БДИ буенча уртача баллары

Фәннәр	2020 ел (уртача БДИ)	2021 ел (уртача БДИ)	2022ел (уртача БДИ)
Рус теле	86,34	87,61	87,13
Математика (профиль)	74,64	78, 54	80,35
Физика	73,1	73,43	74,71
Химия	74,8	78,9	79,26
Тарих	78,89	81,6	81,23
Җәмгыять белеме	78,29	81,13	83,10
Биология	69,54	73,37	74,25
География	80,36	86,82	80,54
Информатика	82,52	83,72	83,37
Рус әдәбияты	82,99	80,26	77,84
Инглиз теле	84,29	88,8	89,41
Немец теле	84		80
Француз теле	92		89,5

АВСТРАЛИЯДӘ ЯШӘҮЧЕ ФИНЗИЯ ГАЗИЗОВА:

«ПАЛЬМА АСТЫНДА ТАЛ-ТИРӘК САГЫНДЫРА»

Илдар Мөхәммәтҗанов

Туган җиреңнең кадерен белер өчен, читкә китеп кара. Балтач районының Смәел авылында туып-үскән, күп еллар телевидениедә журналист булып эшләгән Финзия Газизова әнә шулай ди. Аның Австралиядәге Аделаида каласына күчеп киткәненә дә 4 ел икән инде. Финзия белән көнгерәләр илендәге тормыш, сагыну, тел һәм милләт кадере турында сөйләштек.

Бәхет эзләп...

Татар интернетын якыннан күзәтеп баручылар өчен Финзия Газизова ят кеше түгел. Заманында журналист булып эшләгән ханым, меңнәрчә чакрым Җир шарының аскы ягында яшәсә дә, социаль челтәрләр ярдәмендә меңнәрчә чакрымны бар дип тә белми. Булачак ире белән Казанда танышып, аның белән Австралиягә күченеп китте ул. Яшерми: беренче елларда көнгерәләр илендә бик кыен була. Татарстанда бер урында тик утыра алмаган, гел кеше арасында йөргән журналист, чит җиргә барып эләккач, читлеккә эләккән кош хәлендә кала. Сагынудан күз яшьләре дә аз түгелми. Сабырлыкны гаиләсендә таба.

– Ирем Рифкать Австралиядә 20 елдан артык яши инде. Аның тамырлары Кукмара һәм Балтач якларына барып тоташа. Безне Казанда уртак дуслар таныштырган иде. Шөкер, Аллаһы Тәгалә мине ишетте. Ирем нәкъ күңелем теләгән кеше булып чыкты. Тормыш юлында кыенлыкларны аз күрмәдем. Рифкатем миңа язмышым бүләге булгандыр инде ул, – ди Финзия.

Ире турында озак сөйли ул. Диндә булуы, биш вакыт намаз укуы да аларны бербөтен итә. Улы Азатны тапканда хәле бик авыр булып, исән калсам, аулык ябар идем дип, нәзер әйтә ул. Яулык аны тагын да матурайтып кына җибәргән. Университетта бергә укыган Финзия түгел инде ул хәзер! Чит ил дә үзгәрткән аны. Тышкы кыяфәте белән эчке дөньясы тәңгәл килеп тора.

– Тормышыма шөкер итәрлек. Ирем белән ике бала үстерәбез. Эмилиясе мөселман мәктәбендә укый. Азат бакчага йөри. Әмма атнасына өч көнә көн. Калган көннәрне ул минем белән. Атнага биш тапкыр инглиз телен өйрәнәм. Хөкүмәт читтән килүчеләрне бушлай укыта. Бу вакытта улыбызны тәрбиячегә калдырып торабыз. Анысы өчен дә акча алмыйлар. Казанда укыганда ук махсус курслар үтәсе калган икән, дим. Инглиз теле кая барсаң да кирәк. Баштарак тел белмәгәч, бик нык кыйналдым. Урамда күршеләр очрамасын дип, тиз генә өйгә кереп китә идем. Хәзер инде алар белән рәхәтләнеп сөйләшәм. Табибка барып хәлемне аңлатырлыгым бар. Хәзер тел белгәч, миңа бик рәхәт. Кешеләрнең җылы мөнәсәбәтен тоеп яшим, – ди Финзия. – Ирем исә, киресенчә, рус телен онытып бара. Ул инглиз телендә камил сөйләшә. Татарчасы да яхшы. Читтә яшәүче кешеләр телне кадерли икән ул. Иремнән чыгып әйтәм, ул борынгы сүзләр куллана. Андагы милләттәшләребез шулай сөйләшә, телне нык саклап калган. Ирем әллә кайчангы татар көйләрен тыңлый. Бик милләт җанлы кеше. Үзем дә читтә яши-яши татар телемнең иң якын, кадерле, газиз икәнен аңладым. Белсәгез иде безнең телнең матурлыгын! Элек, Казанда торганда, мин милли бизәкләргә игътибар да итми идем. Хәзер алардан да матур, кадерле әйбер юк. Ә иң кадерле әйбер минем өчен ул – китаплар. Татар китаплары. Австралиягә Казаннан килеп төшкән посылкага ничек сөенгәнне белсәгез! Ул татар китапларын алтынга тиң күрәбез. Әле менә үзем дә китап алып китәр өчен махсус бер чемодан алып кайттым.

Австралия – мигрантлар иле. Бирегә дөньяның төрле илләреннән төрле милләт кешеләре агыла. Финзия сөйләгәнчә, дәүләт аларны берләштереп, уртак җәмгыять төзергә тырыша. Әйтик, елына бер мәртәбә «гармония көне» уздыралар. Бер атна дәвам итә бу бәйрәм. Һәр кеше башкаларны үз милләте белән таныштыра. Атна буе эшкә, укуга милли киемнәрдән йөриләр. Күп булмаса да, әнә шул милләтләр казанында татарлар да бар.

– 500-600 татар бар дип сөйлиләр иде, хәзер меңләп бардыр. Барысын да санап бетереп булмый, милләттәшләребез белән аралашмаганнары да бардыр. Әлбәттә, танылган Вәлиевлар, Садриевлар нәселләре бар. Аларны һәркем белә, – дип сөйли Финзия. – Очрашырга, күрешергә, аралашырга тырышабыз. Бигрәк тә бәйрәм вакытларында. Корбан һәм Ураза гаетендә гаиләләр бер-берсенә кунакка йөри. Бу гадәт татар һәм уйгырларда сакланып калган һәм «гаетләп йөрү» дип атала.

«Язылучыларым белән рәхәт»

Читкә киткәч, Финзия социаль челтәрләрдә язылучыларына андагы тормышын күрсәтә башлады. «Авылда яшәп ятып, без моның кадәр матурлыкны каян күрер идек?! Синең белән бергә йөргән кебек», – ди интернеттагы дуслары. Финзиягә шул кирәк тә! Ул ике арада элемтәне сакларга тырышып, язылучылары өчен төрле бәйгеләр оештыра. Татарча матур фикерләр калдыручылар өчен дә уеннар үткәрә. Бервакыт аңа бер ханым русча яза. Янәсе, татар телем яхшы түгел, русча гына фикер калдырыйм, ди. Ничек булдыра аласыз, шулай итеп татарча языгыз, дип үз сүзендә тора Финзия. Шулай итеп, Австралиядән туган телне искә төшерә.

– Мин язылучыларыма матур урыннарны күрсәтергә тырышам. Көнгерәләрне бик яраталар. Бирегә аларның 69 төре бар, диләр. Ярты килолыдан башлап 90 килога кадәр җиткәннәре дә очрый икән. Беренче тапкыр аны инҗир җыярга баргач күрдем, – ди Финзия.

Кешеләрнең яхшы мөнәсәбәтен күреп шаккатам, ди ул. Австралиядә бер-береңә хөрмәт зур булганга игътибар иткән. Кешеләрне бай – хәерчегә, түрә – хезмәтчегә бүлмәүләре турында сөйли. Бу урында Финзия бер очракны искә төшереп үтте. Казанга кайтыр алдыннан документ эшләре белән йөрергә туры килгән аларга. Нотариус кирәк, ә эш сәгате инде тәмамланган. Ишектә күрсәтелгән телефон номерын җыйгач, трубканы алган ханым аларны өенә чакыра. Баралар, керәләр, тиешле документка кул куела. Чыкканда, бу ханым аларга үзенең визиткасын суза. Укып карасалар, шәһәр мэры өендә йөриләр икән! Финзиябез шакката.

– Кеше мөнәсәбәтләре әле дә гаҗәпләндерә. Шәһәрләрдә хәйрия кибетләре эшли. Ипи пешерүчеләр һәрвакыт анда бушлай икмәк алып килеп тапшыра. Берәү дә аны талашып, сугышып алып бетерми. Киресенчә, үзенә кирәк кадәр ала да китеп бара. Бетүгә тагын алып киләләр. Йортында булган кирәкмәгән җиһазны да урамга чыгарып куялар. Кирәк кеше рәхмәтен әйтеп алып китә, – дип сөйли Финзия. – Монда 90 яшьлек әбиләр дә машина йөртә. Машина йөртү таныклыгы булса да, башта курыктым. 90 яшьлек әбиләр машина йөрткәнне, син йөртмәссеңме, Финзия, дим. Үземне җыйдем. Утырдым да киттем. Машинада йөрү – эсседән котылу чарасы ул.

Татарстан белән Австралия арасындагы вакыт аермасы 7 сәгатьне тәшкил итә. Без йоклаганда, аларда инде таң ата. Ул вакытта инде Финзия торт пешереп өлгергән була. Сагынганда күңелен юату өчен башлаган шөгыле хәзер аңа табыш китерә.

– Беренчесен иремнең туган көненә пешергән идем. Ошаттылар. Аннары махсус укып чыктым. Бу эш өчен рөхсәт тә кирәк әле. Башкаларга тәкъдим иткәч, заказлар да килә башлады. Күңел күтәрелеп китте. Үземә ошаган шөгыль таптым. Елап утырырга вакыт азрак кала башлады, – ди Финзия. – Кем әйтмешли, кәҗәсе түгел, мәзәге мөһим. Бу да – иҗат эше. Тортлар кибеттә дә сатыла. Әмма монда халык кулдан ясалган әйберне якын күрә. Иремнең дуслары еш кына безгә килә. Мин аларны татар халык ризыклары белән сыйладым. Әле күптән түгел генә өчпочмаклар пешергән идем. Берничә көннән соң шул дуслары, ирем аша заказ биреп, тагын өчпочмак пешертеп алды. Мондагы халыкның безнең бар ризыкка исе китә.

Матур булса да торган ил...

Бу ил хакында шулкадәр яратып сөйләсә дә, Финзиянең бар теләге – олыгайган көнендә туган якка кайту. Балалар үстерү, тормыш итәр өчен читтә яхшы булса да, олыгайган көнендә ул үзен Татарстанда күрергә тели. Иренә дә бу хакта әйтеп куйган икән инде. Киләчәктә #Австралиядә татар кызы дигән китап та чыгарасым килә, ди ул.

– Татарстанны сагынганда, минем бик тә хәлвә ашыйсым килде. Мин аны бик озак эзләдем. Австралиядә күп ул. Әмма миңа үзебезнеке, көнбагыш орлыклары салынганы кирәк иде. Сагынуны шул басты. Мин аны бик кыйммәткә – ярты килосын 1 мең сумга сатып алдым, – ди Финзия. – Өч ел кайтмагач, бу юлы бик сагындым. Ул хисләрне аңлату кыен. Актык чиктә күзләремне йомам да авыл урамыннан йөргәнемне күз алдына китерә идем. Күршеләрнең капка төбендә үскән үләннәренә кадәр, хәтта ташларны да сагындым. Татарстандагы бер көнемне дә бушка әрәм итмим. Күңелемә рәхәтлек табып, Казан урамнарын буйлыйм, авылымда ял итәм. Якын кешеләрем, дусларым белән аралашам. Ел буена җитәрлек рухи азык алып китәм. Еллар гына имин торып, очрашулар еш булсын иде!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

КЫШКА ӘЗЕРЛӘНӘСЕЗМЕ?

Лилия МУЛЛАГАЛИЕВА, Татарстанның атказанган артисты:
– Быел җәй тик утырырга да вакыт юк. Әле дә Сабантуйларда чыгыш ясыйбыз. Соңгысы 15 августта үтәчәк. Үз йортың белән яшәгәч, эшнең дә бетәсе юк. Җырлап кайтам да бакчада эшлим. Компотлар ябып куйдым. Ә менә җиләк җыя алмадым. Актанышка да кайтып булмады. Бу атнада абыемның улы өйләнә. Туйга барасыбыз бар. Гаиләмә килгәндә, бар да тәртип. Улым техникум тәмамлап, кабат укуын дәвам итә. Кечкенәләре өйдә инде. Каядыр чит илгә барып ял итүне планлаштырмаган да идек.

Зөһрә НАСЫЙБУЛЛИНА, хат ташучы (Мамадыш):
– Пенсиягә чыкканыма 10 ел була инде, әле һаман эшлим. Авыл кешесе газета-журналсыз калмасын дип йөрим инде. Таратучы булмаса, язылучысы да калмый бит аның. Үзем дә укырга бик яратам. Ел саен кышка әзерләнәбез инде. Бакчабыз тулы сый-нигъмәт. Шәһәрдә яшәүче кызларым кайта да бөтен эшне эшләп китә. Терлекләр дә тотабыз бит әле. Быел печәнне үзебез әзерләмәдек, әзерен сатып кына алдык. Бер төргәген 1 мең сумнан таптык. Иң мөһиме – җан тынычлыгы кирәк. Бер-береңне аңлап яшәсәк, эшкә дә, ашка да күңел үсә.

Тәнзилә ИДИАТУЛЛИНА, сыер савучы (Кукмара):
– Төнге сменадан эштән кайттым әле. Күп итеп җир җиләге җыйдык. Ике бакча печән үстерәбез. Аларны бер кат чабып алдык инде. Икенче каты өлгереп килә. Колхоз да печән тарата. Анысын да урнаштырасы бар. Артык калганын сатабыз. Бакчада кыяр-помидорлар өлгерде. Быел алма да күп. Бу арада кура җиләге җыясым бар. Кызым белән киявем зур йорт салып чыктылар. Озакламый өйләренә Коръән укытачаклар.

Әлфинә ӘХМӘТШИНА, күпбалалы әни (Нурлат):
– Ирем белән дүрт бала үстерәбез. Ишле гаилә булгач, бакчадан кергән дә юк. Быелгы җәй бик ошый. Чүп утауны да яратып башкарам. Инде балалар да миңа булыша башлады. Алар белән бергәләп эшләгәндә, вакыт үткәне дә сизелми, тиз дә була. Башта көннәр бик матур булмады. Ирем теплицаны җылытып биргәч, май аенда ук кыяр ашый башладык. Июнь башында помидор өлгерде. Быел җиләк тә күп булды. Ни генә ясамадык! Аллага шөкер, суган-сарымсак та, кишер-чөгендер дә бик яхшы үсеп утыра. Яңа бәрәңгене дә күптән ашый башладык. Тиздән карбызларыбыз өлгерәчәк. Тырышлык кирәк. Ялкауланып ятсаң, берәү дә китереп бирми.

Нуретдин ФӘССӘХОВ, пенсионер (Мамадыш):
– Яздан бирле урман-кырлардан кайтып кергән юк. Гомерем буе шулай. Башта җиләклекләрне күзәтеп йөрим, өлгергәч, җыярга барабыз. Быел каен җиләге күп тә, эре дә булды. Хатыным белән бер барганда 20шәр литр җыеп кайттык. Кышка үзебезгә җитәрлек итеп әзерләп куйдык. Калганын саттык. Быел аның бәясе дә күтәрелде. Биш литрлы чиләге 1600 сум тора. Бәяне төшермәдек. Теләгән кеше алды. Ир кеше булсам да, яратып җыям. Оят эшкә санамыйм. Бу атнада җиләк бетәр дип уйлыйм. Себерке, мәтрүшкә җыярмын дип торам.

Сәлимә САБИРҖАНОВА, эшмәкәр (Спас):
– Алдан нидер планлаштырма икән ул! Быел диңгезгә барып, ял итәрмен дигән идем. Әмма бар да башкача булды. Җәй башында кинәт кенә күңел болганып, авырый башладым. Ярый вакытында алтын куллы табибларга эләктем. Үт куыгыма таш җыелып, өянәгем кузгалган икән. Бик катлаулы операция ясадылар. Әле ныклап йөри башлавыма 2–3 көн генәдер. Бик авыр кичердем. Сәламәтлекнең кадерен тагын бер кат аңладым. Хәзер миңа тукланууны да үзгәртәсе инде. Яшисе килә бит, анысына гына түзәрбез. Кышка берни әзерләмәдем әле. Сатып кына алырмын инде.

СЫЕРГА ДА УТ КИРӘК

Күптән түгел генә газетабызга «Су кадерен... сусыз беләә» дип, авылда яртышар көн тирәсе су бетеп торгач килеп чыккан кыенлыклар, замана уңайлыкларына тәмам күнегеп бетүебез турында язган идем. Төп фикерем аларның кадерен белү, исраф итмәү турында уйлану да иде. Әлеге язманың «аягы» җиңел булды: узган атнада авылда әле су, әле ут белән мәшәкатьләр килеп чыкты.

12 июль көнне күрше Биктәштә Питрау бәйрәме узды. Ут өзелүнең сәбәбен шуннан күрдек. Үзебезнең авылның түбән очында багана алыштырганнар булып чыкты. Бер сәгать эчендә кабат тоташтырдылар. Иртән торып чыксак, тагын ут юк. Монысы бик күпләргә өстәмә мәшәкать тудырган булып чыкты. Авылларда бит хәзер күпләр берничә сыер асрый, һәр хуҗалыкта диярлек аппарат... Ул көнне сөт җыйнаучылар көндәгедән иртәрәк килде, күрше биктәшлеләр сыерларын сава алмаган, сөт тапшыручылар аз булды, диделәр. Бездә дә сәгать дүрттән иртәрәк абзарга чыгучылар гына аппарат белән саварга өлгергән булып чыкты. Электрчылар эшне тиз тотты үзе. Бер сәгать эчендә тоташтырып та куйдылар. Ике көннән көтү кайтыр алдыннан берьюлы өч авылда ут бетте. Линиядә нәрсәнедер яшен суккан булып чыкты. Бу юлы кичке унберенче киткәнне көтәргә туры килде.

15 июльдә исә сусыз калдык. «Торба тишелгән, су бирәр сәгатьтән була», – дип язды су кудыру насосын карап эшләтүче Гөлүзә. Кичен исә, бик нык яшенләп-күкрәп яңгыр килгәч, әллә районнан ук өзделәр, әллә үзебезнең трансформатордагы автоматлар атты – ярты төнгә кадәр ут булмады. Болытлы булгач, өйдә дә караңгы: гадәттәгечә, фонарьларга зарядка җыйдырылмаган – ярый әле берсе «сафта». Әле ярый шәм запасы бар. Күп тәрәзәләрдә яктылык юк иде, димәк, аларда мондый «хәзинә» булмаган. Кичтән тоташтырсалар да, иртәнге өчтә инде авыл группасына: «Нишләп тагын ут юк ул?» – дип яздылар. Иртәнге тугызларда бу авариянең шактый җитди икәнлеге ачыкланды. Әмма, рәхмәт төшкере, җитәкчеләр чарасын күрде: хуҗалыкның машина-трактор паркындагы генераторны эшләтеп, вакытлыча-вакытлыча булса да, ялгап тордылар. Кичкә кадәр гаебен эзләде электрчылар. Шөкер, көтү кайтышка төзәтеп өлгерделәр. Халык тизрәк сыерларын савып калырга ашыкты.

Ул көнне: «Бездә ут юк әле», – дисәк, танышлар: «Һай, суыткыч-туңдыргычларыгыз нишли инде?» – диде. Тик урамдагы эсселектән дә бигрәк кешеләрне сыер саву күбрәк борчыды. Үч иткәндәй, ут нәкъ менә иртән һәм кичен сыер савар чак җиткәч бетеп тилмертте. Күрше салавычлылар генератор алганнар, шуның белән сауганнар, дип тә, безнең авылда да түбән очта кемдәдер генератор бар икән, шуның белән сауганнар, дип тә әйттеләр. Әмма күпчелек кул белән саудды. Дөресрәге, газапланды. Аппаратка өйрәнгән сыерлар бит әле кул белән саудырмый да, сөтен дә биреп бетерми. Чүмечләп саудык, диюче дә, аппарат белән сауганда чиләктән артык сөт бирә иде, тулып та җитмәде, диюче дә булды. «Без кул белән сыер савудан бизгәнбез икән инде, бер сыерны аппарат белән савып калган идем, берсен сауганчы бармаклар

«ВТ» архивыннан

шеште, кулның хәлләре бетте», – дип аптыраучы да, сыер савышырга туганын чакыручылар да булды. Күп сыерлылар ток булганны көткән булып чыкты.

Күрше Фәйрүзә исә: «Бүген тагын синең аппарат белән саудык, Гөлсинә апай», – ди. Кул белән саудык, диюе. Авылда инде бер сыерлы өч кенә хуҗалык калды, аларның да икесендә аппарат бар. Бер сыерлы, аппаратсыз без генә. «Авылда бер мин генә сыерны кул белән савам икән», – дигән идем, «Түбән очта Гадилә апа әле биш сыерның дүртесен кул белән сава», – диделәр.

Сүз уңаеннан: алтмыш хуҗалыклы авылымда бүген 18 хуҗалыкта гына сыер асрала, шуларның икесе сыерларын көтүгә йөртми. Уналты хуҗалыктан 37 сыер малы көтүгә йөри, әле өйдә торганнары да бар. Бер бетергән кеше кабат сыер асрамый, малны, сөт бәяләре тотрыклы торганга, күбрәк асраучылар гына арттыра.

...Тулы бер атна әнә шулай әле су, әле ут көтеп үтте. Шөкер, зур борчулар булмады, артык озакка китмәде. Бүген әле узган атнада алган сабаклар онытылмады: су акрын килә башлаган кебек тоелса, мунча бакларына, буш савытларга су тутырабыз, фонарьларның да, телефоннарның да зарядларын карап кына торабыз. Аларын шәм белән алыштырып булмый.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

НАЛАСА КЫЗЫ

«Наласа авылы көе» дигәндә, Арча районындагы авыл, халык җыры гына түгел, шул исемдәге әсәр дә хәтердә яңара. Язучы Гүзәл ӘДҺӘМ-ШАКИРОВАның якты әсәрләренең берсе бу. Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясенең әдәби әсәрләр конкурсы җиңүчеләре арасында да аның исеме бар иде. «Үсмерләр өчен хикәяләр» номинациясендә ул беренче, икенче урыннарны алды. Язучы бүген нинди уй-фикерләр белән яши? Әдәбият, бигрәк тә үсмерләр әдәбияты ни хәлдә? Без шушы һәм башка мәсьәләләр хакында сөйләштек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Китап белән укучы арасы ерагаямы, якынаямы?

– Ерагайганнан-ерагая бара. Вазгыяте шундый. Ник дигәндә, китапны укучыга кечкенә чактан гына якынайтып була. Әйтик, безнең буын башлангыч сыйныфларда ук дәфтәр башлап, шунда укыган китапның авторын, кыскача эчтәлеген язып барды. Миндә язучылык, бәлки, шул чакта ук башланып киткәндер дә әле. Без, 20 бала, өченче сыйныфтан башлап, бер-беребезне уздыра-уздыра шул дәфтәрне тутыра идек. Аннан соң укытучылар, бәлкем, дәфтәр алып баруны таләп тә итмәгәндер, ә мин шактый еллар язып бардым әле. Бервакыт авылга кайткач, чормадан шул дәфтәрләрне табып алдым. Бер зур пакет иде ул. Бер карасаң, бик зур хезмәт инде. Хәзер исә мәктәпләрдә бер сәгать татар теле, бер сәгать әдәбият укытылганда, китап укуны, дәфтәр башлап язып баруны таләп итеп тә булмыйдыр. Укытучы ничарадан бичара фәнгә өстән-өстән кыскача күзәтү ясаса гына. Ә бит баланы иң башта китап укырга күнектерергә, укуны гадәткә әйләндерергә кирәк. Күнегеп китмәсә, ул инде кулына китап алып утырмаячак.

:: Укучыны югалтмас өчен, язучы нәрсә эшли ала?

– Укучыга якынаю өчен, башта китабының чыгуы кирәк. Ә китабы чыккан язучы – ул бәхетле язучы. Минем китап та чыкмый бит әле. «Наласа авылы көе» дигән китабымны 2011 елда үз хисабыма чыгардым. 2012 елда шул ук китапны Татарстан китап нәшрияты бастырды. 2017 елда балалар өчен «Әбием ни исемле?» дигән китабым чыкты. 2018 елда ул «Ел китабы» конкурсында иң күп укылган балалар китабы булып танылды. Соңгы китабым 8 нче ел чыкмыйча ята. Бу – бик кәефне төшерә торган нәрсә. Мин хәтта башка бернәрсә дә язмыйм дип ант итеп, өч ел кулыма каләм алмадым. Булган әсәрләрне социаль челтәрләргә урнаштыра башлаган идем, баксаң, кызыксыналар, укыйлар икән. Шуннан Татарстан Президенты каршындагы тел комиссиясенең бәйге игълан итүе күзгә чалынды. Тоттым да «Үсмерләр өчен хикәяләр» номинациясендә үз көчемне сынап карарга булдым. Әсәрләрем беренче һәм икенче урынны алды. Стимул ул язучыга да, укучыга да кирәк. Язучы укучы ихтыяҗын матбугат аша да канәгатьләндерә ала. Бу җәһәттән миңа «Ватаным Татарстан», «Мәйдан» журналы хәерхаһлы булды. Укучыны югалтмас өчен, язучы бер генә нәрсә эшләргә – иҗат итәргә тиеш. Калганы – нәшрият, башка структуралар, шул ук укытучылар эше. Мин моны әдәбият укытучысы буларак та әйтәм.

:: Сез әдәбиятка соңарып килеп кердегез кебек.

– Аның сәбәбен әйтсәң, кеше ышанмас та инде. Кечкенә вакытта мин яздым. «Яшь ленинчы», «Ялкын» журналларында хикәяләрем чыга иде. Әтием – укытучы, үзе дә каләм тибрәтә. Ул миңа, син язарга тиеш, дип әйтә килде. Арча педучилищесында укыганда да яздым әле мин. Аны тәмамлагач, Казан дәүләт университетына, Гүзәл яза да ул, бәлки язучы булып китәр дип, юллама бирделәр. Университетта укыганда исә язуым бөтенләй тукталды. Каләмгә мин 2008 елда гына тотындым. Чөнки университетта укыганда театр белән җенләнүем шулкадәр көчле булды: мин артист булырга тиеш дип, төрле театр түгәрәкләренә йөри башладым. Спектакльләрдә катнаштым, концертлар алып бардым. Юллама белән Актаныш районына барып чыккач, үзебез халык театры оештырып, ун ел буе спектакльләр куеп йөрдек. Аннан гаиләбез белән Алабугага күчендек. Анда да укытучылар коллективы белән театр оештырдык. Балалар студиясен булдырдык. Ахыр чиктә ике вуз дипломым булса да, Алабугада яшәп, ничек инде театр бүлегендә укымаска дидем дә, анда укырга кердем. Ул чакта өч бала анасы идем инде. Әмма Алабугадагы бер күренекле кешенең мине сәхнәгә чыгарасы килмәде. Хәтта концерт барышында, инде сәхнәгә чыгарга әзер булып торганда, сезне сыздылар, дип килеп әйткәннәре булды. Әлбәттә, мин аңа хәзер рәхмәт укыйм. Ник дигәндә, ул миңа энергиямне әдәбиятка юнәлтергә мөмкинлек бирде. Камал театры «Яңа татар пьесасы» конкурсын игълан иткәч, пьеса яздым. Шул ук елны нәфис фильм сценариена конкурс игълан иттеләр. Анда Фәнис Яруллин белән миңа өченче урынны бирделәр. Шуннан дәртләнеп киттем. Аннан килеп, минем бит төп эшем укытучы. 30 елдан артык педагогик эшчәнлегемдә, 20 ел Алабуга педагогия институтында доцент, филология фәннәре кандидаты буларак хезмәт куйган кеше. Әмма артист булу хыялыма, күрәсең, нокта куелмагандыр. Менә быел да «Татар сүзе»ндә сәхнәгә чыктым һәм «Проза» номинациясендә беренче урынны алдым. Узган елны «Мәсәл» номинациясендә икенче урынны алган идем.

:: Сезнең иҗатыгызда документаль әсәрләр шактый. Әйтик, Әлифба авторлары Рәмзия Вәлитова белән Сәләй Вәгыйзов истәлегенә багышланган повестегыз бар.

– Һәр әсәрдә документаль җирлек була. Әйтик, «Наласа авылы көе» дигән әсәр шушы җырны тарихта калдыру өчен язылды, дисәк тә ялгыш булмас. Аны әтинең тормышындагы вакыйгаларга бәйләп чыгардым.

Минем әти Донбасста туган. Әби белән бабай әтигә 10 яшь булганда гына авылга әйләнеп кайтканнар. Бу гайре табигый хәл түгел. Безнең авыл кешеләре өчен кышка таба Донбасска чыгып китү гадәти булган. Әби белән бабай да шулай итеп озын берлек артыннан чыгып киткәннәр.

> Әти үзенчәлекле кеше иде безнең. Нинди уен коралында уйнарга теләсә, шунда уйный ала иде. Әле дә хәтерлим: мин икенче сыйныфта укыганда, капка-коймалары җимерелеп диярлек беткән иске генә йортыбызга Казаннан пианино алып кайтып куйды. Һәм шул пианинода уйнарга да өйрәнде. Авыл кешеләре «Әдһәмнең зур гармуны» карарга дип, безгә килә иде.

Пианинoны әнә шулай, «зур гармун» дип атадылар. Аннан соң скрипка алды, анда да уйнарга өйрәнде. Курайда уйнау, гармунның төрлесен алып, аларда уйнау – барысын да булдырды. Әби дә гармун уйнаган. Донбасста чакта баракларны җыештырганда, берәүнең гармунын кулына алып, шыпырт кына өйрәнгән булган. Сугыш вакытында әбинең тальянын бәрәңгегә алмаштырганнар. Әти кич белән безне авылны урап кайтырга алып чыга иде. Түбән Аты тавының бер урынына җиткәч: «Әни менә шушы урында авылга карап гармун уйнады», – дип, гел искә ала иде. Ул гармун кайда икән, исән микән дип, үзенең әллә ничә төрле уен коралы булса да, гел шул гармунны уйлады. Әбинең авылга карап гармун уйнавы әсәргә әнә шулай кереп китте.

Әлифба авторлары Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия апа Вәлитова шәхесләренә багышланган әсәрем – «Меңнәрнең берсе» повесте. Әти Сәләй Вәгыйзовта укыган, мин педучилищега кергәндә, ул инде лаеклы ялга чыккан иде. Әти аңа, яратып, Сәләй Гатич дип эндәште. Әтидән нинди генә эштә ярдәм сорама, ул булыша. «Кайдан беләсең син моны?» – дисәң, «Безне бит Сәләй Гатич укытты!» – дип җавап бирә иде. Тагын бер генә сүз: әти белән әни үзләре дә картаеп, пенсиягә чыккач та, Сәләй Гатичларны ел саен Укытучылар көне белән котлап кайталар иде.

:: Сез – Язучылар берлеге әгъзасы. Андагы хәлләрне күзәтеп барасызмы? Татарстанда Россия бүлеге оешуга карата фикерегез нинди?

– Берлек эшчәнлегендә актив катнашам дип әйтә алмыйм. Чакырсалар, әлбәттә, кире какмаячакмын. Ә берлекләрнең урчүенә мин бик сагаеп карыйм. Безнең бер, әмма берәгәйле берлегебез бар. Татар язучылары болай да күп түгел бит инде. Ә инде Мәскәү берлеге безгә отышлырак, ул өстенлекләрне күбрәк бирә, дигән сүзләргә шәхсән үзем ышанмыйм. Алар үзләрендә генә дә берничәгә таркалган... Хәер, бу мәсьәләдә мин – кечкенә кеше инде.

:: Татар әдәбияты ни хәлдә?

– Татар әдәбияты элек тә начар түгел иде, хәзер дә хәлебез әйбәт. Элек тә төрле дәрәҗәдәге әдәби әсәрләр туа иде, хәзер дә шулай. Һәм аларның бөтенесе дә кирәк. Дөрес, кайбер жанрлар сүнеп бара. Әйтик, үсмерләр әдәбияты кытлык сизелә. Ә бит ул – үсеп килүче буынга иң зур йогынты ясый ала торган өлкә. Бигрәк тә хәзер, балалар кечкенәдән кырыс булып үскән заманда үсмерләр әдәбияты алга чыгарга тиеш, минемчә. Күңелләрен нечкәртү, мәрхәмәтлелек орлыгы салу өчен кирәк ул. Юкса бит компьютер уеннары, синең әле берничә гомерең бар, дигән фикерне сеңдерә. Ә бит гомер бер генә, аның кадерен белеп, барысына да җитешергә тырышып яшәргә кирәк. Телевизордагы ни кеше, ни җан иясе булмаган геройлар бала психикасын нишләтә? Матурлыкны күрергә өйрәтәсе юкса...

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Блиц-сораштыру

– Холкыгыз буенча сез – нинди кеше?

– Күндәм. Артист буласым килә, дигәч, әни: «Кызым, укытучы – артист инде ул», – диде. Һәм мин күндем. Укытучы булу нияте белән, башта педучилище, аннары Казан университеты, рус теле укытучысы булырга тәгаенләнгәч, педагогия институтын тәмамладым. Без – әти-әнигә каршы сүз әйтмәскә дип тәрбияләнгән буын. Шуңа күрә, бернича мөмкинлек чыкса да, театр юнәлешенә кереп китмәдем.

– Иң зур теләгегез нинди?

– Минем яшьтәге хатын-кызның теләге бер генә була: балалар, гаилә имин булсын. Минем ирем бик әйбәт, мин аңа көненә ун тапкыр яратам дип әйтәмдер, мөгаен.

– Татар кешесе яратуын кычкырып әйтергә кыенсына бит ул.

– Ихлас сүзләрне кычкырып әйтүдән оялмаска кирәк. Балалар әти белән әнинең бер-берсен яратуын тоеп, күреп үссен. Минем әти белән әни әйбәт яшиләр иде. Әмма алар азрак кына ачуланышса да, бик бәләкәй чагымда, үлсәм ярар иде, дип теләгәнем истә. Имеш, мин үләм дә, алар шул кайгыдан татулаша. Менә шуңа күрә яратам дип әйтүдән кыенсынмаска кирәк.

< Дәвамы. Башы 15 июль санында

Гөлсем дәшмәдә, акча түлим, дисәләр дә, ул шымчы роленә ризалашмас иде. Түрә апай сәхнәдә артистларга әмер бирәмени, «роль»гә яңадан-яңа вазыйфалар өстәде.

– Күргәннәреңне сәгате-минуты белән аерым блокнотка сызгала!

Аның сүзсез генә елмаеп куюын ризалык билгесе дип уйлады, ахрысы, «эт анасы» кулын чәбәкләде:

– Килештек, кызкай!

Урам чатында прогулка тәмамланды. Минкия Марсовнаның «балалары» уянып, «мамочка»ларын эзләр, имеш. Күршеләрем белән танышам дип дәртләнгән Гөлсем шушы кыска гына араладан да арган, ә алда күзгә күз терәп яшисе озын-озын көннәр, айлар, еллар... Өеңдә генә бикләнеп ятасыңмы, җүләр?

Кичә түрә ханымны, ялын бүлдертеп, эшенә чакырттылар. Тәрәзә урам көзгесе иде: няня Маша әнчекләрне куалап йөри, «балалар» шыр «ялангач». «Блокнотыңа теркә...» Сәер апай син, Марсовна!

– Кайсы төштә өзелдем мин, кызым? – диде ул, маңгаен уып.

– Сталин сәдәфе, Солтанморат бабай.

– И мин, тишек баш! Дөрес, кызым. Менә син бүген аш кашыгы белән чумырып-чумырып кара уылдык ашыйсыңмы?

Карт баягы йомгакны чуалтты бугай дип, хатын төзәтергә ашыкты:

– Сәдәф, бабай, сәдәф...

– Сабырсызланма, кереш өлеш монысы. Саташмый бабагыз! Бүлнистә сестра дисеңме? Зарплат әз сезнең. Димәк, кара уылдык тәтеми сиңа. Миңа да тәтеми, пенсиям бәләкәй. Кибет киштәсендә күреп, күзем генә туена. Вәт балачакта аны ашап махмырлый идем. Мәскәүдә тудым мин. Эти метро төзелешендә эшләде, әни өй тавыгы иде. Күрше фатирдагы Коля дәдәй белән дус иде эти. Серләре килештә аларның. Икесе дә сугышта катнашкан, фронтовиклар. Берсендә, кара янып, Коля дәдәй керде. Бер кулында – озын муенлы шешә, икенчесендә – әлеге дә баягы затлы күчтәнәче – уылдык. «Утлы су»ын кырлы стаканнарга коя да күлмәгенең җиң очын исни. Ка-

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ҖИР ЙОТМАГАН

(ХИКӘЯ)

Танышу дәвам итте: уң канаттагы күрше белән урамда очраштылар. Таякларын карчыгына тоттырып, арттан ияргән картны ул беренче сәламләде:

– Ни хәлләрдә, бабай?

– Яхшы гына, кызым. Җан күршебез ни атлы икән?

Җан күрше! Нинди матур сүз!

– Мин – Гөлсем, бабай.

– Без – Солтанморат. Карчыгым Мәүлидә белән шушы бистәдә ярты гасыр элгәре төпләндек. Ызбабыз искерде, үзебез дә искердек. Врачлар миңа, буранмы, кармы, яңгырмы, теркелдә, бабай, итү аяк буыннарың ката, диләр. Аякларны теркелдәтәбез анысы, вәләкин урамда иптәшлеккә кеше юк. Сүз алышырга, дим. Һәркайсы үз өенә бикләнгән. Тел тутыга минем, сөйләшмәсәм, кызым. Мәүлидә: «Колагымны тондырасың, лыгырдамасана», – дип тирги.

Чүлдә кәрванчы суга сусаса, бу карт сүзгә сусаган, шул ук вакытта ул аны сабыр гына тыңлаган берәр кешегә дә мохтаҗ иде шикелле.

– Минкә белән бик якынайма, кызым. Бистәдә аны «Черная вдова» диләр. Өч ир күмде, тегеләр нилектән үлгән? – Аптыраш. Тап-таза ирләр үзләре. Скорпион Минкә, астыртын чага. Саклан, кызым, син бик юаш күренәсең. Мине чагалмый, шүрли, чөнки дә бабагыз – яшьлегендә Сталинның мундир сәдәфен капшаган егет! Аның гайрәте иңгән миңа, шайтаннан да курыкмый бабагыз. Кызым, сәдәф турында шаккаткыч әйбер сөйлим хәзер.

Карт, дәртләнеп, хикәятен башлаган гына иде, капка төбендә карчыгы сыбызгы сызгыртты.

– Әһә, төшке ашка, диләр. Оныкның шул уенчыгы белән тәки уйнады, кортка. Син йөри тор, кызым. Мин тиз генә капкалыйм, яме?

Мөгаен, тамак хәсрәте яшьлек хатирәсеннән көчлерәктер дисәң, ашауны кыска тотты бабай, Гөлсем урам әйләнгәндә туп кебек тәгәрәп каршысына килеп тә җитте.

бымлыксыз гына коры авызга шешәнең яртысын бушаткач, аю төсле үкереп елый бит күрше абзый.

– Атабыз үлгән, атабыз! Скоро дөнья җимереләчәк!

Эти кырыс кына:

– Шаяртмасана, Коля! Атаңның вафатына биш былтыр, – диде.

Коля дәдәй кызарган яшьле күзен этигә төбәде:

– Ты че, не понял что ли? Синең белән минем Сталин атабыз үлгән!

Бүген безнең оныклар фейк дип ят сүзләр кыстыра, мәгәр бу заманда яшәсә, эти дә шулай дияр иде. Ата коммунист кисәк кенә дустының бугазыннан эләктерде:

– Ялган!

Коля дәдәйнең күз алмасы оясыннан атылды. Буып үтерә! Ул гыр-гыр итеп:

– Мин тәп-тәгәл беләм, – диде һәм үзенең үтә дә яшерен серен ычкындырды. Күрше абый өч хәрефле оешмада хисаплана икән. Ә безнең өчен ул заводта токарь санала иде. Әллә кем дә түгел, погонлының шоферы икән. Әнә шул погонлының югарыдагылар белән пышылдашканын үз колагы белән ишеткән. Ил-көндәге яңалыкларны, моның ишеләрне аерата, гади халыкка минут эчендә җиткермиләр, кызым. Расланды әлеге кара хәбәр: Коля дәдәй белән этинеке генә түгел, миллионнар атасы якты дөнья белән хушлашкан иде. Этигә үпкәләмәде күрше абый, элеккечә дус булдылар. Без дә аның серен сатмадык, «токарь» икән «токарь».

Минем һәр тишеккә, һәр ярыкка борын тыгарга яраткан үсмер чак. Унөч яшь. Олыларның тар гына кухняда серләшкәнен мыек очына (һи, нинди мыек ди, сыңар төк тә үсмәгән!) чорнап барам. «Гумар, давай мин сине чиратсыз-нисез Мавзолейга апкерәм, син – коммунист, иптәш Сталин белән исәнләшерсең, ул Ленин белән янәшә тере кебек ята», – дигәч, колагымны шомрайттым. Йә, эти нәрсә дияр? «Рәхмәт, Николай, мәетне кем сәламли инде? – дип турыдан ярды эти. – Алай үтереп кыстагач, малайны апкер. Яшьләр кемнең кем икәнен танып үссен».

Мин пырдымсыз «апкер, Коля дәдәй» дип, аш бүлмәсенә атылдым. Чүт кенә янмадым шунда, кызым. – Карт иякен чөеп көлде. – Эти кызу канлы иде. «Әллә син безне тыңлап торасыңмы, малай актыгы», – дип бәргәләп ташлар иде, «токарь» яклады:

– Аның теле йозакта, әйеме, Султанмурат? Җыен, иртәгә аппарам!

«Әллә кем түгел» Коля дәдәй, «әллә кемнең әллә кеме!» икән лә. Елан сыман уралып-уралып сузылган чиратта көнозын аяк талдырасы, ә күрше абзый сакчыларга кызыл кенәгәсен күрсәткән генә иде, без һич тоткарлыксыз эчкә уздык. Ике бөек юлбашчы янәшә йоклый, Сталин кичә генә йокыга талган кебек, валлаһи дим. Үз төсе, үз кыяфәте. Ике нәрсә исемдә: аның куллары һәм ялтыравык мундир сәдәфләре. Ишегалдындагы яшьтиләр белән тәмәке тарткач, эти, ачуланып:

– Яңак төбеңә берне ямар идем, кул кыска, – дигән иде, ә Сталинның кулы киресенчә озын, менә ул күзен ярым ачар да, «җүнсез малай» дип, маңгайга кундырыр төсле иде.

Пыяла табут янында ярты секунд та тукталырга ярамый, чират боз өстендәге чаңгыдай тиз шуыша. Алай да мин сәдәфләрне санап өлгердем. Бишәү!

– Аһ син, алдакчы! – Артта Мәүлидә карчык куа, чын мәгънәсендә куа, яшь кызлар да болай йөгермәс иде. – Бакчадагы беседкада черем итәм дип ялганлый бит. Тагын Ысталин сәдәфеме? Ышанма син аңа, сеңлем, борчак сиптерә, карт тиле! Әкият ул!

– Әй, йөземне кызартма инде, пешкән алмам. Әле син Сталинның үзен дә әкият диярсең.

– И-и, әкият кенә булсачы! – Карчыкның да хәтере тутыкмаган икән. – Безнең эти авылда мулла иде. Калхуз җыелышында персидәтел: «Җәгез, туганнар, таралышыйк! Яшәсен бөек Сталин!» – дигәч, эти: «Яшәгән хәтлесе җиткәндер, Аллаһы әкбәр», – ди. Икенче көнне аны өтермәнгә яптылар. Вәт нишләтте Ысталинныкылар, без – биш баланы ятим калдырды.

Икәү талашмый, йомшак каз мамыгы белән генә бер-берсен сыпыра кебек иде. Алар парлы... Алар бәхетле... Иңгә иң куеп, бергә картаялар. Ә Гөлсемнең гомер күпереннән җитәкләшеп атлыйсы юлдашы күкләргә ашты... Иренең җанын кыйган адәм актыгы кайларда икән бүген? Бәлки җир түзгәндер-түзгәндер дә йоткандыр аны? Хәер, җир андый бәндәләрдән җирәнәдер ул...

Әче тәтен өердертеп, урамнан фил хәтле соры машина «очты».

Солтанморат карт:

– Сәдәф, – дип хикәятен дәвам итмәкче иде, карчыгы янбызына төртте:

– Бабасы, кем икән бу?

– Кем, кем! Козгын үзе. Чит илдә кышлый да, җылыткач кайта. Алҗыдым, пешкән алмам, керик сәнә.

Соры машина үң яктагы йорт каршысына туктады. Өченче күрше! Козгынмы ул, чыпчыкмы – барыбер танышасы.

– Чү әле, бабасы, – Мәүлидә карчык кулын кашына тигезләде. – Күз дә начарланды. Эте дә бар моның. Тегесе алабай яман тешли иде. Монысы бозау хәтле овчарка, бабасы. Хуҗасына охшаса – өзеп атыр. Аллам, Козгын иләмсез симергән.

Гөлсемнең дә күзе әйле-шәйле генә күрәме соң? Юк, булмас! Ул чыра кебек ябык иде, ә бу ир иләмсез таза. Булмас! Тынычлан, җүләр хатын! Син биргә үткәннәрең белән хушлашыр өчен күчендең ләбаса.

Дәвамы бар >

Шигърият

Фәнис ЯРУЛЛИН

КЕШЕ КИРӘК

Эшли-эшли арыганда,
Бәлаларгә тарыганда,
Бер назлауга сусаганда,
Янда дус-иш булмаганда –
Юатырлык кеше кирәк.

Бәхет эчкә сыймаганда,
Хезмәт җимешен җыйнаганда,
Минем белән чын күңелдән
Шатланышыр кеше кирәк.

Ялгыштым, дип үкенмәслек,
Авыр диеп чигенмәслек,
Нинди генә хәлләрдә дә
Дошманына сер бирмәслек
Кеше кирәк! Кеше кирәк!

(1967)

* * *

Әй, яшисе килә матур итеп,
Рәнҗетмичә хәтта гөлне дә,
Ялган, мәкер, үч һәм ачуларны
Якын китермичә өемә.

Беркемгә дә ачу тотмыйм үзем,
Ләкин бар шул миңа үчләләр.
Упкын булып, авызын ачып тора,
Мине йотар өчен көнчеләр.

Көнләшерлек җирем дә юк кебек,
Яшәмимен алтын сарайда.
Шигырь язам бары. Шигырь белән
Учак кабызамын мин Айда.

Шул учакның яктылыгы кирә,
Тәрәзәләр аша ачылып.
Бер нур җитә кайчак, тормыш уты
Китсен өчен җанда кабынып.

Әзме җирдә якты бер нур көтеп,
Җанына очкын көтеп яшәүче?
Вакытында шул очкынны тапса,
Язгы яшен булып яшьнәүче?!

Мин кабызган утлар арткан саен
Арта бара кара көнчелек.
Таш атканга ташлар атар идем,
Таулар төшүе бар ишелеп.

(2003)

БЕРДӘНБЕРЕМ

Бу дөньяда, әни, син бердәнбер,
Була алмый синең алмашың.
Көнне көнгә бәйләп, син һаман да
Безнең белән бергә барасың.

Акыллының иң-иң акыллысы,
Матурларның иң-иң матуры,
Тыйнакларның иң-иң тыйнагы син,
Сабырларның иң-иң сабыры.

Җаның аша барсын уздырасың,
Сизгерләрнең дә син сизгере.
Кылдан нечкә, кылычлардан үткен,
Синең йөрәк – сират күпере.

Син үлемсез, әни, бу дөньяда,
Бездә синең гомрең дәвамы.
Без яшибез икән, син дә исән,
Үлем ала алмый Ананы.

(2002)

Сабантуй төрле кеше күзлегеннән

(Уены-чыны бергә)

Зур түрә:
Сабантуй – татар халкының борынгыдан килгән бәйрәме. Ул халыкны берләштерә. Халык бердәм булганда гына без бердәм булабыз. Бердәмлектә – көч! Көчтә – куәт!

Блогер:
Сәлам, дуслар! Миннән гел сорыйлар кайда син дип. Сабантуйда әле мин. Лайк куегыз!

Җырчы:
Юл өстендә тагын берәр Сабантуй юк микән кереп җырлап чыгарга?

Дин әһеле:
Элек андый бәйрәм булмаган.

Авыл җирлеге башлыгы:
Быел бүләккә ничек акча табарга инде?

Авыл халкы:
Сабантуйга зарплата бирмәсләрме?

Шәһәр халкы:
Без кайттык. Әйдә, биегез!

Әз-мәз мәзәк

– Мин, үлеп, акча яратам.
– Ә мин аларны әле башкалардан көнлим дә!

* * *

Ике егет кафеда утыра.
– Официант! Ике чәй алып килегез әле, – ди берсе.
– Стаканы чиста булсын! – дип өстәп куя икенчесе.
Берничә минуттан официант ике чәй алып килә:
– Чиста стакандагысы кайсыгызга әле?

* * *

Бу тормышта без кем генә булсак та, урманга гөмбәгә барганда без барыбыз да яшәргә урыны булмаган сукбай кыяфәтендә.

* * *

Гадәттә, кыш көне эшләргә салкын булган әйберне җәй көне эшләргә эссе.

* * *

Кешенең 32 күзе булса, офтальмологлар стоматологлардан баерак булыр иде.



Сканворд җаваплары

Горизонталь: Сак, мур, Фәридә, нур, җим, Әнкәй, Вадим, Диләрә, зәһәр, ас, АМО, гармун, ТТ, Минһаҗ, чалма, ант, Нәби, мат, март, бина, ху, Фирая, ланч, Мазда, куб, ана, Артур, катамаран, горур, адаш, та, ит, ил, бу, Марат.

Вертикаль: Кама, Ив, Миндияр, мамонт, Бату, тиз, Ания, Сафин, мәрҗән, Гамил, балук, кирмән, чи, абага, карга, Тошиба, Мәдинә, Алмачуар, тур, уйдырма, мут, ра, яр, матәм, Арарат, Алсу, акр, намаз, яра, дан, Әстерхан, Ту.

Беләсең килсә

1 Гөлчәчәкнең бу сорты иң кыйммәтлеләрдән санала. Аны дөньяга тудыру өчен 15 ел кирәк булган.
а) Джульетта;
б) Клеопатра;
в) Ләйлә.

2 1999 елның 31 декабрендә үзенең мөрәҗәгатендә Президент Борис Ельцин нәрсә диде?
а) Я устал. Я ухожу;
б) Я ухожу. Я сделал всё, что мог;
в) Я ухожу. Не серчайте.

3 Габдулла Кәримов – татар әдәбиятына 20 нче еллар башында килгән шагыйрьләрнең берсе. Ул нинди тәхәллүс белән билгеле?
а) Кәрим Кара;
б) Бай Кәрим;
в) Ярлы Кәрим.

4 2011 елда эшләнелгән бу әйбер 5,5 метрны тәшкил итә, аның авырлыгы – 37 кг. Зурлыгы өчен аны Гиннесс рекордлар китабына кертәннәр.
а) каләм;
б) шырпы;
в) сосиска.

Җаваплар: 1. а); 2. б); 3. в); 4. а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 16052 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 304

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+